АЛМАЗ ХИСАМЕТДИНОВ:
«Безнең өчен иң куркынычы – читтән алып кайткан терлек»

> 6

ТӘМЛЕ ҺӘМ ТИЗ
Курьер хезмәтенә ихтыяҗ ни өчен зур?

> 7

ГАДЕЛЛЕК КОРБАНЫ
Шпионнар эзләүгә каршы чыкмаса, милли хисләрен яшереп йөртсә, бәлки, исән калган булыр иде...

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 1 (29161) | Җомга | 5 гыйнвар | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

АЛУ БЕЛӘН БИРҮ АРАСЫ

БЫЕЛ АКЧАГА БӘЙЛЕ НИНДИ ҮЗГӘРЕШЛӘР КӨТЕЛӘ?

Яңа елга яңа өметләр белән керү – гадәти хәл. Иш өстенә куш дигән сыман, Аждаһа елы күпләр өчен финанс ягыннан да уңышлы булачак икән. Ә төрле ышануларны читкә куйсак, Яңа ел акча янчыгына нинди яңалыклар алып килде? 2024 елда безне нәрсә көтә? «ВТ» хәбәрчесе акчага кагылышлы быел гамәлгә кергән һәм керәчәк яңалыкларны барлады.

> 5

Ишетми калмагыз

Татарстанда һәм Россиянең башка төбәкләрендә Президент сайлаганда, бюллетеньнәр салынган сейф-пакетларны махсус маркалар белән саклаячаклар.

Махсус маркалар Россия Федерациясенең барлык субъектларында да кулланылачак. Аларның берничә саклау дәрәҗәсе бар: марка өслегендәге люминесценция элементлары, уникаль тәртип номеры һәм яңадан ябыштыру мөмкинлеген булдырмый торган махсус кирт. Маркаларны «Гознак» әзерләячәк.

Инде билгеле булганча, Россия Президентын сайлау өч көн (15–17 март) узачак.

Татарстанда көннәр тагын да суытачак. 4–9 гыйнвар аралыгында республикада аномаль салкыннар көтелә. Синоптиклар шулай дип кисәтә. Аномаль салкыннар аркасында, республикада хәтта шторм кисәтүе игълан иттеләр. Татарстан Гидрометеорология үзәге мәгълүматларына караганда, җомга, шимбә көннәрендә көндез –18...–24 градуска кадәр салкын булуы көтелә. Төнлә –28 градус, урыны белән –34кә кадәр суыта. 7–9 гыйнварда көннәр бераз җылыначак. Ул көннәрдә көндез –18 градус, төнлә –19...–24 градус, урыны белән –30 градуска кадәр салкын булачак.

Яңа ел каникулында Татарстан лагерьларында 5,6 меңнән артык бала ял итә. Биредә алар өчен спорт, иҗат, белем бирү юнәлешендә күпсанлы чаралар әзерләнгән. Татарстан яшьләр эшләре министры Ринат Садыйков сүзләренә караганда, авыр хәлдә калган балаларга аеруча зур игътибар бирелә. Бүген республика лагерьларында шундый 297 бала исәпләнә. Махсус хәрби операциядә катнашучыларның балалары да – игътибар үзәгендә. Узган ел республиканың мәктәп яны лагерьларында әтиләре хәрби операция зонасына киткән 2268 бала ял иткән.

Казан федераль университеты бюджет урыннары саны буенча Россия югары уку йортлары бишлегенә кергән. Бу хакта Россия мәгариф һәм фән министрлыгы хәбәр итә.

Гомумән алганда, яңа уку елына Россия югары уку йортларында 620 меңнән артык бюджет урыны каралган. Төбәкләрдәге вузларга барлык бюджет урыннарының 70 проценты туры килә. Бюджет урыннары «Сәламәтлек саклау һәм медицина фәннәре», «Машина төзелеше», «Информатика һәм исәпләү техникасы», «Электр һәм җылылык энергетикасы», «Биология фәннәре», «Электроника, радиоэлектроника һәм элемтә системалары», «Мәгълүмати куркынычсызлык», «Математика һәм табигать фәннәре», «Авыл хуҗалыгы һәм авыл хуҗалыгы фәннәре» юнәлешләрендә арткан.

Районнарда ни хәлләр?

Менделеевск

Россия Президенты Владимир Путин Менделеевскида туган лейтенант Данат Насыйбуллинны бүләкләгән. Ил башлыгы хәрбигә Ярыгин пистолеты һәм фрак билгесе – Россия Президенты штандартын тапшырган. Билгеле булганча, яңа елның беренче көнендә Владимир Путин Новое Огарёвода махсус хәрби операциядә катнашучылар белән очрашты, алар төшке аш вакытында аралашты.
(«Менделеевск яңалыклары»)

Аксубай

Аксубай кызы Юлия Еремеева Россиянең иң гүзәл чуваш кызы дип табылган. XIII Бөтенроссия «Россиянең чуаш чибәре-2023» бәйгесендә Татарстан, Башкортстан, Чувашия республикаларыннан, Ульян өлкәсеннән 18 иң чибәр кыз катнашкан. Алар бәйгедә чуаш телен, чуаш халкының тарихын, мәдәниятен һәм традицияләрен белүләрен, иҗади сәләтләрен күрсәтергә тиеш булган. Татарстан данын яклаган Юлия Еремеева бу бәйгемнәрнең барысын да уңышлы башкарып чыккан. Республиканың чуаш яшьләре лидеры, республика Халыклар дуслыгы йорты методисты булып эшләүче якташыбыз узган елның мартында «Нәүрүз-2023» бәйгесендә «Нәүрүз гүзәле» исеменә лаек булган иде.
(«Авыл таңнары»)

Арча

Яңа елның икенче көнендә Яңа Кенәр авылында яшәүче Сәгыйдәбану Хәбибуллинага 100 яшь тулган. Йөзьяшәр әбине район башлыгы Илшат Нуриев та котларга килгән, юбилярга Россия Президенты Владимир Путинның һәм үзенең Рәхмәт хатларын, бүләкләр тапшырган. Сәгыйдәбану әби 1924 елның 2 гыйнварында Кышлау авылында (хәзер Әтнә районына керә) туган. Хезмәт юлын туган авылында хат ташучы булып башлый, аннан соң тракторчы булырга да туры килә. 1955 елда ире Габделхәй белән Яңа Кенәр авылына күченәләр. Промкомбинатта кирпеч цехында эшли, ире столяр була. Сәгыйдәбану балалар бакчасына эшкә керә, җәйге айларда аш пешерүче була. Габделхәй абый – Бөек Ватан сугышы ветераны, 2001 елда вафат.
(«Арча хәбәрләре»)

Әгерҗе

Әгерҗе районындагы «Ласка» балалар приютында тәрбияләнүчеләр озын бәйрәм ялларын саваплы гамәл белән уздырырга булган. Биредәге бер төркем бала бу көннәрдә махсус хәрби операциядә катнашучы егетләргә балаклава тегү белән мәшгуль. Узган елның декабрендә алар егетләргә бер партия балаклава тегеп җибәргән булган инде.
(«Әгерҗе хәбәрләре»)

ЯКТЫ ӨМЕТЛӘР УЯТА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ РӨСТӘМ НУРГАЛИ УЛЫ МИҢНЕХАНОВНЫҢ РАШТУА БӘЙРӘМЕ УҢАЕННАН КОТЛАВЫ

Православие динендәге хөрмәтле ватандашлар!

Сезне тантаналы Раштуа бәйрәме уңаеннан тәбрик итәм.

Бу бәйрәм дин тотучыларның күңелендә якты өметләр, рухи яңарышка, игелеккә һәм шәфкатьлелеккә омтылыш хисләре уята. Хәзерге авыр сынаулар чорында җәмгыятьтә мондый изге гамәлләргә ихтыяҗ тагын да арта, милләтенә һәм диненә карамастан, һәркем аларны йөрәгенә якын кабул итә.

Раштуа – зур дини бәйрәм булу белән беррәттән, кешенең якыннары, газизләре турында кайгыртуы ни дәрәҗәдә мөһим булуын янә бер кат раслый торган гаилә бәйрәме дә. Бу исә гаиләне, аның традицион рухи хәзинәләрен яклауны киңрәк җәелдерү максат итеп куелган Гаилә елында аеруча тирән мәгънәгә ия.

Узган елда республиканың православие динен тотучылары тормышында зур вакыйгалар булды. Дин гыйлеме бирелә торган илдәге иң борынгы учреждениеләрнең берсе – Казан дини семинариясенең 300 еллыгын бәйрәм итү шул чараларның иң әһәмиятлесе. Башкалабызда күпсанлы кунаклар, дин әһелләре, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре катнашуында узган Татарстан Республикасы православие җәмәгатьчелегенең V форумында соңгы еллардагы үсешкә йомгак ясалды.

2024 ел хәерле эшләргә шулай ук бай булыр, игелек юлында ирешкән казанышларыбыз күңелебезгә нур һәм сөенеч өстәр дип ышанам.

Сезгә чын йөрәктән бәйрәмчә күтәренке рух, бәхет, иминлек һәм уңышлар телим.

ЮЛ ДӘРЕСЕ

Кечкенә авылларга вак таштан юл салу, Шәле – Баулы юлы төзелеше һәм җәмәгать транспортындагы «куян»нарга каршы көрәш. Татарстан транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Хәнифов 2023 елга йомгак ясады. Ул М12 автомобиль юлын салучыларга рәхмәт әйтте һәм былтыр башкарып чыга алмаган эшләр турында сөйләде. «ВТ» хәбәрчесе министр әйткән төп фикерләрне туплады.

М12 трассасы

Автомобиль трассасын салу турында сөйләшә генә башлаганда, бу эшне 2025 елга башкарып чыгарга ниятләгәннәр иде. Аннары төзелеш тәмамлану вакытын 2024 елга күчерделәр. Узган елның җәендә исә эшне ел азагына ук төгәлләргә мөмкин икәне ачыкланды. Шулай эшләделәр дә. Мондый кыска вакыт аралыгында, ә бу 800 чакрымнан артык юл, илдә мондый төзелешнең башкарылганы юк иде әле. Татарстан аша әлеге юлның 142 чакрымы уза. Автомобиль трассасын өлешләп кулланышка тапшыру да үзенаклады.

Бораулау өчен кирәкле җайланмаларны бөтен Татарстан буйлап җыйдык. Ничек кенә булмасын, җиңдек. Юл салучыларның җаваплылыгына үзем дә шаккаттым. Аларның уңганлыгына рәхмәттән артык сүз юк.

Шәле – Баулы юлы

Шәле – Баулы автомобиль юлы М7 һәм М5 федераль трассаларын тоташтырачак. Аңа озынлыгы 145 чакрым тәшкил иткән Алексеевск – Әлмәт юлы да керә. Трассаның бу арасын быел ук кулланышка тапшыру күздә тотыла. М12 юлы кебек, Алексеевск – Әлмәт юлын да өлешләп, мәсәлән, кайсыдыр борылышка кадәр, ачу тәкъдиме бар. Хәзер бу мәсьәлә өйрәнелә. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Казан – Мәскәү трассасы ачылгач, икенче көнне үк Алексеевск – Әлмәт юлын сынап карады. Ул үзе рульгә утырды. Алексеевскидан Әлмәткә 1 сәгать 15 минутта барып җитте. Юлның сул як өлешен инде җыеп бетергәннәр дияргә ярый.

Калган эшләр

2023 елда авылларга вак таштан юл салу эшен киң кулланылышка кертеп җибәрә алмадык. Татарстанның берничә районында моны эшләп карадык, яз көне әлеге юлларның сыйфатын тикшерәчәкбез. Мондый юллар республикадагы вак таштан төзелә, арзан да, тиз дә. Республикадагы 500гә якын кечкенә авылда әлегә таш юл юк. Мин үзем дә – районда эшләгән кеше. Кечкенә авыллар гадәттә табигатьнең иң матур почмагында урнашкан була. Анда урман да, инеш тә, елга да бар. Менә бүген глэмпинглар өчен юллар төзибез. Кечкенә авылларыбыз теләсә нинди глэмпингтан яхшырак югыйсә. Тагын бер хәл ителмәгән бурыч – цемент-бетон юллар төзелешен кире кайтару. Алар кыйммәтрәк, әмма озаккарак, 50 ел һәм аннан да күбрәк вакытка чыдый.

Җәмәгать транспорты

Безнең алда катлаулы бурыч тора, ул – җәмәгать транспортын яхшырту. Бу өлкәдә сыйфатлы система булмаса, Казан «бөке»ләргә батачак. Үзегез уйлап карагыз, Татарстан башкаласында юлларга шәһәр мәйданының нибары 1,33 процент өлеше туры килә. Мәскәүдә әлеге күрсәткеч – 4, Нью-Йоркта – 11 процент. Казан юлларын бушату өчен, җәмәгать транспортын мөмкин кадәр арттырырга, ә шәхси автомобильләрне киметергә кирәк. Шәһәр юлларын ничек тә булса бушатасы иде. Татарстан быел 400дән артык автобус сатып алачак. Шул исәптән Чаллыга – 90, тагын 12 районга – 119 автобус. Күбесе Казанда калачак. Түгә 25 автобус республикага кайтты инде. Без аларны махсус казначылык кредитлары һәм дәүләт транспорт лизинг компаниясе программасы ярдәмендә сатып алабыз. Әмма төп шарт – алар камералар, электрон түләү һәм пассажирларны исәпкә алу системалары, ягъни телематик җайланмалар белән җиһазландырылган булырга тиеш. Бүген Татарстанда 1,8 мең автобус эшли, аларның 1,5 меңе көн саен юлга чыга.

Олы юл төзегәндә тузган юллар

М12, шулай ук М7, Шәле – Баулы юллары төзелеше барышында күп кенә төбәк һәм муниципаль дәрәҗәдәге юллар файдаланылды һәм хәзер дә файдаланыла. Шунысын да әйтик: аларның сыйфаты начарая башлады. Чөнки зур техника йөргәч, кечкенә юллар изелеп тә бетте. Шөкер, М12нең эшен бетердек. Шуңа күрә быел ук Кайбыч, Югары Ослан кебек районнардагы олы юл төзелеше барышында файдаланылган юлларны тәртипкә китерүгә тотыначакбыз. Ә инде М7 һәм Шәле – Баулы юллары салынып беткәннән соң, 2025 елда бирелә кулланылган юлларны да төзекләндерергә вәгъдә бирәбез.

Эльвира ВӘЛИЕВА

«АКЫЛСЫЗ ЕЛЛАР» БУЛАМЫ?

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

«Акылдан язган дүрт елдан соң нормаль елга өметләнеп буламы?» дигән сорауга дөньяның иң бай кешеләреннән берсе – инвестор Илон Маск социаль челтәрдә: «2024 ел тагын да акылсызрак булачак, менә сезгә минем фаразым», – дип җавап бирде. Әйе, 2024 елда вакыйгаларның тагын да кискенләшәчәгенә бу юлларның авторы да шикләнми. Әмма мәсьәләнең башка бер ягы бар бит монда: кешеләр ни өчендер бәхеттә яки бәхетсезлекләрдә елларны гаеплиләр. Әйтик, бу көннәрдә социаль челтәрләрне ачсак, «Яңа ел безгә бәхетләр алып килсен» дигән күпсанлы язуларга тап булабыз.

Стоп, шушы урында туктыйк та аз гына рациональ акылны эшкә җигеп алыйк әле. Нәрсә ул – Яңа ел һәм аның безне бәхетле яки бәхетсез итәргә мөмкинлеге бармы? Без «ел» дип Җир шарының Кояш тирәли якынча 365 көндә әйләнеп чыгуын әйтергә күнеккәнбез. Стартны Җир шары 31 декабрьнең төнге сәгать унике тулган мизгелендә башлый дип санасак, финишка да шул минутларда килеп җитәчәк. Әйләнеш бик төгәл исәпләнгән, чынлыкта 365 тәүлектән 0,25 тәүлеккә озаграк бара, шуңа күрә дүрт елга бер тапкыр без февральне 29 көн итәбез. Болай үзе планета ел саен бер тизлектә әйләнә, ялгышмый, акылдан да язмый. Адәм балалары ни өчендер шул әйләнештән нәрсәдер өмет итәләр: тормышта уңай үзгәрешләр булыр кебек тоела. Стартны 31 марттан дип исәпләсәк, яңа әйләнеш 1 апрельдән башланыр иде. Һәм, ышаныгыз, бу безнең тормышка бәхет тә, бәхетсезлек тә өстәмәс иде. Старт алынганда, күп итеп ашау, акылны җуйганчы эчү шулай ук проблемалардан башка берни дә өстәми. Бу юлларның авторы бөтенләй башка принциплар буенча кора тормышын, шуңа күрә вакыйгаларның үзгәрүендә көннәрнең, айларның, елларның хәлиткеч бернинди дә катнашы юк дип саный.

Тормышта акылсызлык, мәгънәсезлек арта икән, ел түгел, кешеләр үзләре гаепле. Телеграм-каналларның берсендә соңгы көннәрдә генә бер хәбәр күзгә чалынып китте: тарихта беренче тапкыр җенесен алыштырган хатын-кыз, ир буларак, шулай ук җенесен алыштырган ир кешегә (хәзер инде хатынга) өйләнде, диделәр. Дөрес аңлавыгызны сорыйм: эш бер парның юләрләнүендә генә түгел. Кешеләр психикасы бик бозылды хәзер, авышулар массакүләм төс алды. Без аны әлеге хәбәрнең тантаналы рәвештә игълан ителүеннән дә чамалый алабыз. Рим католик чиркәвенең Яңалыклар агентлыгы китергән янә бер хәбәрне карыйк. «Ватикан, – диелә анда, – гомосексуаль парларның никахын хуплады». Хәзер чиркәүдә никах процедурасы үткәргәндә, парларны ир белән хатын дип игълан итеп, рухани: «Кайсыгыз – ир, кайсыгыз – хатын?» – дип сорарга мәҗбүр булачак. Хәтта гадәти парлар никахлашканда да кайсының – ир, кайсының хатын булачагын өзеп әйтеп булмый бит әле монда. Күпмедер вакыт үтүгә, аларның башына җенес алыштыру уе килмәс, дип кем әйтә ала? Рәсми пропаганда бу юнәлештә хәзер бик кызу темплар белән һәм актив эшли. Ниндидер явыз көч Җир шарында идарәне үз кулына алырга һәм, кешеләрне акылдан яздырып, алар белән ни теләсә, шуны кылырга җыена. Монда иске елның да, яңа елның да бер катнашы юк. Акылдан яздыру тормышның барлык өлкәләрен иңли: җенси азгынлык мактала, ирек дип тамгалана; кешеләрне акча колы итү өчен зур тырышлыклар куела. Процентлы кредит һәм отыш уеннары аша гамәлгә ашырыла ул. Кредитоманнарның акылы шулкадәр җуела: телефон мошенниклары, аларны куркытып, алдап, миллионлаган суммада акчаларын талыйлар. Талаучылар арасында академиклар, генераллар, зур оешма җитәкчеләре бар. Иң соңгы корбаннарның берсе – Сталин бертуганының улы (племянник) Леонид Аллилуев декабрь ахырында гына стресстан һәлак булды. Ул мошенникларга 18 миллион сум акча түләгән инде, шуннан соң да аның банк картасын тагын ике тапкыр талаганнар.

vk.com

Ашау-эчү, ризык мәсьәләсендә дә безне юләрләндереп, төп башына утыртырга гадәтләнделәр. Бәяләр күтәрү турында түгел әле сүз, чын ризык урынына ясалма ризыклар белән баш әйләндерәләр. Албания, Британия, Бангладеш, Пакьстан базарларында ясалма йомыркалар пәйда була башлады. Аларның бәясе чын йомырканың 20 процентын гына тәшкил итә, диләр. Димәк, ихтыяҗ булачак һәм, ихтимал, яңалык озакламый Россия базарларына да килеп җитәр. Ялган йомырка белән чынын аеру алай кыен түгел икән: ясалма йомырканың кабыгы яна, чынныкы – юк. Кешеләрнең үз теләкләре белән алданып, сәламәтлек өчен зыянлы продуктларны сатып алуында ничек итеп яңа яки иске елны гаеплисең?

«Бөтен планетаны иңләп алган золым һәм явызлыкка каршы торуның бер юлы да юкмыни?» – дип сорар, бәлки, язманы укучылар. Бар, әлбәттә. Явызлыкка каршы чыгуның нәтиҗәле һәм оттырышсыз юлы бар: ул – игелек кылу һәм адәм балаларын шуңа өндәү. Өндәүне берәү дә кабул итмәсә дә, изгелеккә чакыру туктатылмаска тиеш. Бу – яшәешнең мөһим законы. Бер мисал белән раслыйк фикерне. Бала таба алмаган кысыр хатын, тәрбиягә бала алса, күп вакытта балага уза. Табиблар аңа инде, өздереп, кискен диагноз куйган була, әмма карында яралган сабый ул диагнозларны чәлпәрәмә китерә. Ләкин хатынның омтылышы риясыз булырга тиеш, балага узарга дигән ният белән алмаска тиеш ятимне. Эчкерсезлек – игелек кылганда хәлиткеч шарт. Менә бу темага эзләнгәндә, миңа шундый вакыйга сөйләделәр. Хатын белән ир, үз балалары булудан тәмам өмет өзелгәч, тәрбиягә бала алалар. Һәм... могҗиза: озак та тормый хатын балага уза. Ләкин хәзер инде үз балалары буласын белгәч, карар үзгәрә: «Ник кеше баласын тәрбиялик, үзебезнекен үстерербез», – дип, тәрбиягә алган баланы кире кайтарып бирәләр. Карындагы бала үлә, аны ярып алырга, бәхетсез ананың аналыгын да алып ташларга туры килә. Хәзер инде ул берничек тә балага уза алмаячак һәм тәрбиягә баланы да берәү дә бирми, чөнки барлык балалар йортларында да гаилә – кара исемлектә. Җәза бик гадел, читләрне гаепләрек түгел. Яшәүнең асыл мәгънәсе дә, яратылышның максаты да шуңа барып тоташа. Аллаһы Тәгалә ачык күрсәтә ул максатны: «Мүлек» сүрәсенең беренче-икенче аятьләрендә барлык хакимлекнең Аллаһ кулында булуын искәртә, үлемне һәм яшәүне кешеләрнең кайсы изге гамәл кылуда өстенрәк булуын сынап белү өчен бар итүен әйтә.

Язучы сүзе

Могҗиза

Бу дөньяда хәтсез яшәп, күпне күргән кеше буларак, мин могҗизага ышанмыйм. Бер дә юктан гына бер нәрсәне дә китереп бирмиләр. Алып китәргә мөмкиннәр әле, тик биреп китмиләр. Ләкин могҗиза булсын өчен, аңа ышану мәҗбүри түгел. Могҗиза көтү өчен дә шулай икән.

Үзем ышанмасам да, күңел көтә. Юл буе ашханәләре янында йөргән берәдәк этләр була бит... Ишек янына җитүгә, алар күзенә мөлдерәп карап, каршыңа килеп басалар. Өрмиләр дә, тешләмиләр дә, бары тик мөлдерәмә күзләрен сиңа төбәп көтәләр генә. Кайчагында мин күңелне дә әнә шундый эткә охшатам. Ырламый да ул, шыңшымый да, бары тик өмет тулы күзләрен могҗизалар чыга торган күренмәс ишеккә төбәп, нәрсәдер көтә, шыгырдау тавышы ишетсә, койрыгын болгый-болгый шунда елыша. Дөньяга яңа ел килеп керә торган ишек шәйләнә башласа, бигрәк тә. Яңа ел керсен, дип ачылган ишектән бөтен могҗизалар килеп тулыр сыман кылана.

Әле яңа ел килеп җиткәнче үк ул ишекне кемдер ачып карый бугай. Халык җыелганмы, әзерме, тамашаны башларга мөмкинме дип, чаршау читен шудырып, залга караган артист шикеллерәк инде. Шул әзерлек тикшерү өчен ачылган ишектән генә дә дөньяга бәйрәм рухы кереп тула: нур ургыла, сафлык чорный, тәмлетатлы исләр шаярыша... Шундый хәлдә, могҗизага бер тамчы ышанмасаң да, аны көтәргә мәҗбүр буласың.

Башта ул ил өстенә сафлык дулкыны, нур булып таралыр сыман тоела. Әнә шундый якты дулкын узар да кешеләрнең күзен томалап, башлары өстендә торган кара болытлар эреп таралыр. Хәвеф-хәтәр, шом, курку белән тулып, җиргә кадалган карашлар яктырыбрак китәр. Кешеләр бер-берсенең күзләренә карый алырлар, бер-берсен күрә алырлар. Хокук сыман кысылып, көннән көнгә кечерәя барган иреннәргә елмаю кунар да шатлык булып бар дөньяга сибелер. Тормыш ягымлылык, җылылык белән тулыр. Хәтта соңгы арада кешеләр белән бер каршылыксыз идарә иткән ахмаклык һәм нәфсе дә үзләренең артыклыгын тоеп, акрын гына үз сазлыкларына шуышыр. Аларга әрсезлек, гамьсезлек кебек малай-шалайлар иярер...

Юк инде... Уйларыңның могҗизадан узып, акиятка әверелә баруын тоеп, тыелып каласың. Тирә-ягыңа каранып аласың... Нидер челтерәп киткән кебек була. Әйе! Нәкъ шулай булырга тиеш бугай. Шәһәр читендәге зур вилланың ачкычлары шулай челтери бугай. Өр-яңа «Мерседес» ачкычы белән бергә челтерәтсән, нәкъ шундыйрак тавыш чыга бугай. Аларны сиңа кемдер китереп бирергә мөмкин бит инде бу могҗизалы мизгелдә. Син хәтта шул ачкычларны тотып, мерт-мерт атлап килгән гүзәл сынны да күргәндәй буласың. Тик ул, карашларың көченә түзә алмыйча, чәлпәрәмә килеп коелып төшә.

Хыял ул шулай булырга тиештер инде. Югарыдан, күз күреме җитмәс биеклектән башлана да акрын гына түбәнәя бара һәм үзеңнең тәңгәллеккә төшеп җиткәч, юкка чыгып, котылгысыз чынбарлыкка әверелә. Могҗиза да шулай. Хәтта хыялыңа да сыймаслык могҗиза ул була алмый да, булса да, могҗиза булмый. Һәрбер тылсым үзеңә таман булсын...

Иртән торасың менә... Йокың туйган, бер җирең авыртмый, дәртең ташып тора. Безнең белән яшьтәш могҗизаның иң зурысы менә шушы бугай инде. Ул арада кухняда хатыныңның шалтыр-шолтыр килеп йөргәнен ишетеп шунда керәсең дә сокланудан катып каласың. Ул яшәргән. Нәкъ менә син гашыйк булган чактагы гүзәл кызга әверелгән. Ул да чиксез гаҗәпләнү белән сиңа текәлә. Димәк, син дә...

Менә шундый җилбәзәк уйлар белән Яңа ел бәйрәме узып та китә. Көч-хәлгә башыңны күтәреп, ары-бире йөренәсең дә тәрәзәгә күз саласың, урамнан әйләнеп керәсең. Бер нәрсә дә үзгәрмәгәненә тәмам ышангач, моңсу булып кала. Бушлык. Зарарлы бушлык түгел инде ул, бии-бии күңелне алгысыткан ахмак уй-хыялларның аяк эзләре генә бугай. Тиздән алары да юкка чыгар. Һәм син яңа елның иске чынбарлыгы буйлап атлап китәрсең. Ә анда... Могҗиза кануны гади генә: көтелмәгән хәлләр күп булмасын дисәң, күпне көтмәскә кирәк.

Марат КӘБИРОВ

Әйтеп кенә бактым

Ыгы-зыгы

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Яңа ел алдыннан күкәй тирәсендә ыгы-зыгы купты. Купмас иде, «бәясе күтәрелә икән» дигән хәбәр таралып, халыкның кәефе төште. Күкәй мәсьәләсен хәтта Россия Президентына да җиткерделәр, Владимир Владимирович, мәсьәләне өйрәнербез, хәл итәрбез, диде. Күкәйгә бәя күтәрелү Президент хәтле Президентка барып җиткәч, Мәскәү телеканалларында тапшырулар әзерли башладылар. Без кемнән ким, дигәндәй, Татарстан да читтә калмады: күкәй буенча белгечләр чакырып, телевизордан сөйләштеләр.

Рәхәтләнеп карап утырдык. Җитәкчелекнең халыкны авыр хәлдә калдырмасына ышаныч тагын да артты. Шул ук вакытта күңелгә «күкәй мәсьәләсе нужәли шул хәтле җитди икән...» дигән уйлар да килде. Түзмәдем, үзебездән ерак түгел «Магнит» кибетенә бардым. Кассада якташым Розалия утыра иде. «Нәрсә, матурым, күкәйгә кытлык мәллә?» – мәйтәм.

– Юк, Риман абый, әнә өч төрле бәядән бар, күкәйгә өзеклек булмады. Бераз бәясе күтәрелде, әлбәттә, ну күкәй өстәл янына утырган саен авыз тутырып ашый торган ризык түгел бит инде, – диде.

Әмма без – көтелмәгән яңалыкларны көтеп алып, ыгы-зыгы куптарырга өйрәнгән халык. Күкәй белән дә шулай булды, кеше башында бүтән кайгы калмады, күкәй мәсьәләсе беренче урынга чыкты. Илдә, дөньяда барган зур вакыйгалар да әһәмиятсез, кечкенә мәсьәләгә әйләнде. Ә менә күкәй!

Шул ук Розалия сөйләп торды әле, йомырканы кибеттән 10 данә сыярлык матур тартмаларда саталар бит инде. Соңгы көннәрдә һәр тартмада берәр күкәй югала башлаган. Киләчәктә бөтенләй бетсә нишләрбез, күкәйсез яшәү – яшәү түгел дипме, әллә бәяләр тагын күтәрелмәгәе, дип куркыпмы, халык кибеттән күкәй урлап, запас җыя башлаган. Бу хәлне дусларга сөйләгәч, кайберәүләр шаркылдап көлде, кайберләре сагаеп калды. Башында тавык мие булмаса, бу хәлләрдән тавык үзе дә көләр иде. Бәлки, күкәе өстенә утырып елар иде. Әле үз продукциясенә көндәшлек артуын белми тавык. Әнә беркөнне телевизордан кытайларның ничек күкәй ясавын күрсәткәннәр. Моны сеңлем Роза караган. «Ясалма күкәйләргә кычкыргә туры килер микәнни, абый?» – ди. Аны тынычландырдым инде. «Әнә Азәрбайҗаннан күкәй кайтардылар бит, хәзер Төркиядән көтәбез. Дошман илләр безгә карата күпме генә этлек эшләргә тырышса да, дус илләр безне күкәйсез калдырмас», – дидем.

Яңа ел алдыннан кем генә хыялланырга яратмый инде! Мин әле киләчәктә йә Кытайда, йә башка илдә, ә бәлки үзебездә робот тавыклар уйлап чыгармаслармы дип тә шикләнәм. Тавык сыртындагы төймәгә басасың да җып-җылы бер күкәй тәгәри дә төшә. Әле тавыш белән идарә ителә торган робот-тавыклар да эшли башламагайлары. «Әй, курица, давай десять штук!» – дип кычкырасың да, берсеннән-берсе матур ун күкәй тәгәрәп килә дә төшә. Без ясалмалык заманына килеп кердек кебек, ясалма интеллект булдыру, яшәешебезнең төрле өлкәләренә роботлар кертү турында сүзләр күерганнан-куера. Кайбер илләрдә хәтта ясалма ит җитештерүләре турында да ишеткән бар. Шуларны уйлыйм да: «Яшәсен тавык, яшәсен чын күкәй!» – дип кычкырып куясы килә. Шул ук вакытта безне яңа елда нинди яңа ыгы-зыгылар көтә икән, дигән уй да күңелне кымтырыклап куя. Үзең булып, ихлас булып яшәүгә, үзең җитештергәнне ашауга, куллануга ни җитә инде ул!

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

НОГМАНОВ РАФИЛ ГАБДЕРӘФЫЙК УЛЫ

(01.07.1949 – 02.01.2024)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге зур югалту кичерде.

2024 елның 2 гыйнварында озакка сузылган авырудан соң 75 нче яшендә милиция генерал-майоры, Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министрлыгының элеккеге урынбасары – иҗтимагый иминлек милициясе хезмәте начальнигы Ногманов Рафил Габдерәфыйк улы вафат булды.

Р.Г. Ногманов 1949 елның 1 июлендә Татарстан АССРның Апас районы (хәзерге Кайбыч муниципаль районы) Салтыган авылында туган. Совет Армиясе сафларында хезмәт иткәннән соң, хезмәт юлын 1970 елда Казан шәһәренең Киров районы Эчке эшләр бүлеге милиционеры булып башлый.

1973 елда Алабуга урта махсус милиция мәктәбен, 1981 елда СССР Эчке эшләр министрлыгы академиясе Мәскәү филиалының Казан бүлеген тәмамлый.

1975 елдан 1981 елга кадәр Татарстан АССР Эчке эшләр министрлыгының Җинаятьчеләрне эзләү идарәсендә төрле вазыйфаларда эшли. 1981–1989 елларда Әгерҗе районы Эчке эшләр бүлеге һәм Әлмәт шәһәре Эчке эшләр бүлеген җитәкли. 1989–1993 елларда Җинаятьчеләрне эзләү идарәсе начальнигы урынбасары, Татарстан АССР Эчке эшләр министрлыгының Профилактика хезмәте идарәсе начальнигы була, аннары Чистай шәһәре Эчке эшләр бүлегенә җитәкчелек итә.

1993 елда Р.Г. Ногманов Татарстан Республикасы эчке эшләр министры урынбасары – иҗтимагый иминлек милициясе хезмәте начальнигы итеп билгеләнә. Бу вазыйфада 15 елдан артык эшләп, ул республикада хокук бозуларны булдырмый калуның күпбаскычлы системасын булдыруга зур өлеш кертә. Тәртип саклау иҗтимагый пунктлары эшен яңадан җанландырып җибәрүне башлап йөрүчеләрнең берсе була. Аның җитәкчелегендә милиция участок уполномоченныйлары хезмәтен ныгыту һәм аларның социаль-көнкүреш мәсьәләләрен хәл итү буенча масштаблы эш башкарыла.

Р.Г. Ногманов берничә тапкыр Төньяк Кавказ территориясендә контртеррористик операцияләр үткәрү буенча берләшкән гаскәрләр төркеме составында була. Хезмәт бурычын үтәгәндә күрсәткән кыюлыгы һәм батырлыгы өчен Р.Г. Ногманов Батырлык ордены белән бүләкләнә.

2009 елдан IV һәм V чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты булып тора, даими профессиональ нигездә эшли, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе урынбасары була. Парламентта эшләү чорында Р.Г. Ногманов үз тәҗрибәсен хокук бозуларны булдырмый калу өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын үстерү өчен кулланды. Җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итүгә гражданнарның кушылуына, халык дружиналары оештыруга юнәлдерелгән законнар аның турыдан-туры катнашында эшләнде һәм кабул ителде.

2020 елдан 2023 елга кадәр Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары була.

Р. Г. Ногмановның күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм казанышлары югары дәрәҗәдәге бүләкләр белән билгеләп үтелә. Алар арасында «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены; Жуков, «Җәмәгать тәртибен саклауда аерылып торган өчен», «Санкт-Петербургның 300 еллыгы истәлегенә», «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә», «Фидакарь хезмәт өчен», «Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медальләре, «Россия Федерациясе Эчке эшләр органнарының атказанган хезмәткәре» һәм «Татарстан Республикасының атказанган юристы» исемнәре һ. б. бар.

Р.Г. Ногманов профессиональлек һәм намуслылык үрнәге иде. Куелган максатка ирешүдә нык торуы, сайлаган эшенә бирелгәнлеге, үз идеалларына һәм карашларына тугрылыгы, шулай ук кешеләргә игътибарлы мөнәсәбәте аңа хезмәттәшләре һәм җәмәгатьчелек арасында лаеклы абруй һәм танылу китерде.

Ногманов Рафил Габдерәфыйк улы турында якты истәлек безнең йөрәкләрдә мәңгегә сакланачак.

Р.Н. МИҢНЕХАНОВ, М.Ш. ШӘЙМИЕВ,
Ф.Х. МӨХӘММӘТШИН, А.В. ПЕСОШИН,
Ә.Ә. СӘФӘРОВ, Р.В. ГЫЙЛЬМАНОВ,
А.В. ХОХОРИН, И.Р. МЕТШИН, В.А. СӘЛИМОВ,
А.И. РӘХМӘТУЛЛИН, З.Р. ВӘЛИЕВА

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, полиция генерал-майоры, Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры урынбасары (1993–2009 еллар), IV (2009–2014 еллар) һәм V (2014–2019 еллар) чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты

НОГМАНОВ Рафил Габдерәфыйк улының вакытсыз вафат булуына бәйле рәвештә, туганнарының һәм якыннарының тирән кайгысын уртаклаша.

Бу дөньядан эш сөючән, компетентлы җитәкче, ярдәмчел һәм башкаларга игътибарлы кеше китте. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе урынбасары буларак, Р.Г. Ногманов республиканың административ законнарын үстерүгә зур өлеш кертте, хокук бозуларны булдырмый калу мәсьәләләре белән шөгыльләнде, сайлаучылар мәнфәгатьләрен актив яклады.

Кайгырабыз һәм кире кайтарып булмаслык югалту ачысын уртаклашабыз. Без олы йөрәкле һәм сизгер җанлы кешене югалттык. Рафил Габдерәфыйк улы Ногманов турында якты истәлек безнең йөрәкләрдә мәңгегә сакланачак.

«Таттелеком» компанияләр төркеме коллективы, «Таттелеком» ГАҖ генераль директоры киңәшчесе

Рафил Габдерәфыйк улы НОГМАНОВның вафат булуы сәбәпле, тирән кайгы хисе белән чын күңелдән аның туганнары һәм якыннарының авыр кайгысын һәм кире кайтарып булмаслык югалту ачысын уртаклаша.

Рафил Габдерәфыйк улы үзен югары квалификацияле, энергияле һәм җаваплы җитәкче итеп күрсәтте. Максатларына ирешүдә нык торуы, эшенә тугрылыгы, кешеләргә игътибарлы мөнәсәбәте аңа хезмәттәшләре һәм җәмәгатьчелек арасында лаеклы абруй һәм танылу китерде. Рафил Габдерәфыйк улы турында якты истәлек безнең йөрәкләрдә мәңгегә калачак.

Рафил Габдерәфыйк улы 1949 елда Кайбыч районында туган, Татарстан Республикасы эчке эшләр органнарында озак хезмәт стажына (40 елга якын) ия. 2009 елдан ТР Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе урынбасары була. 2019 елда «Таттелеком» компаниясенә генераль директор киңәшчесе вазыйфасына күчә, 2021 елның апрелендә генераль директорның Икътисадый куркынычсызлык буенча урынбасары итеп билгеләнә. Компаниянең икътисадый куркынычсызлыгын, финанс һәм башка активларының, төп фондларның бөтенлеген тәэмин итү аның җаваплылыгында була. 2023 елның гыйнварыннан генераль директор киңәшчесе булып тора.

Рафил Габдерәфыйк улының күп бүләкләре бар. Ул хезмәт эшчәнлегендәге казанышлары өчен Батырлык ордены (1996), «Фидакарь хезмәт өчен» медале (2008) һәм «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены (2019) белән бүләкләнгән. «Татарстан Республикасының атказанган юристы» (1999) һәм «Россия Федерациясе эчке эшләр органнарының атказанган хезмәткәре» (2006) исемнәренә ия.

Эльвира ВӘЛИЕВА

АЛУ БЕЛӘН БИРҮ АРАСЫ

<Ахыры. Башы 1 нче биттә

Пенсия

Бу елның 1 гыйнварыннан пенсиягә чыгу яшенә бәйле чираттагы үзгәрешләр үз көченә керде. 2019 елда башланган реформаның (ә ул 2028 елга кадәр гамәлдә) дәвамы бу. Шулай итеп, 2024 елдан ир-атлар – 63, хатын-кызлар 58 яшьтән лаеклы ялга китәчәк. Пенсия алу өчен ким дигәндә 15 ел хезмәт стажы һәм 28,2дән ким булмаган пенсия баллары да кирәк. Быел картлык буенча пенсия алучыларның акчасы да артты. Яңалык барлык эшләмәүче пенсионерларга кагыла. Аларның акчасы 1 гыйнвардан 7,5 процентка индексацияләнде. Ил күләмендә картлык буенча иминият пенсиясе уртача 1,6 мең сумга артып, уртача 23,4 мең сумга җитәчәк, дип фаразлана.

Социаль пенсия исә ел да 1 апрельдән арта. Быел әлеге төр түләү – 7,5, 2025 елда – 9,5, 2026 елда исә 10,3 процентка артыр дип көтелә.

Бала түләүләре

Билгеле булганча, бу елның 1 гыйнварыннан инвалид бала тәрбияләүче әти-әниләргә, эшләгән очракта да, тиешле түләүләрне алу хокукын бирделәр.

Яңа елның тагын бер яңалыгы ана капиталына өмет итүчеләргә кагыла. Моннан ары әлеге төр түләүне бала туганчы үзләре Россия гражданнары булган һәм туу хокукы буенча сабый Россия гражданлыгы алган әти-әниләргә генә бирәчәкләр. Сүз уңаеннан, быел ана капиталы беренче балага – 631 мең, икенче балага 834 мең сум булачак.

Декрет түләүләренә дә акча өстәлә. Быел йөклелек һәм бала табу буенча пособиенең максималь күләме 566 мең сумга җитәчәк. Игезәкләр табучыларга тагын 220 мең сумга якын акча өстәлә. Йөклелек буенча отпуск өчен түләү (140 көнлек ял) киләсе елда – 794 мең, 2026 елда 883 мең сум тәшкил итәчәк. Яшь ярымга кадәр бала караган әти-әниләргә иң күп айлык түләү, моңа кадәр эшләгән очракта, 49 мең сумга җитәчәк. Быелтыр ул 33 мең сум чамасы иде. Сабый белән өйдә утыручыларны алга таба тагын да зуррак сөенче көтә. Киләсе елда әлеге төр пособиене – 69 мең, ә 2026 елда 77 мең сумга кадәр җиткерү каралган.

Сан

Быелның 1 гыйнварыннан хезмәт өчен түләүнең минималь күләме (МРОТ), 18,5 процентка артып, **19 мең 242 сум**га җитте. Чагыштыру өчен: 2023 елда әлеге күрсәткеч **16 мең 242 сум** иде.

Башка төр пособиеләр

Россия һәм Хезмәт Геройлары, ветераннар, инвалидлар, блокададагы Ленинградта яшәгән һәм башка кайбер төр категориягә керүчеләргә пособие күләме ел саен 1 февральдә арта. Быел ул – 7,5, 2025 елда – 4,5, 2026 елда исә 4 процентка үсәчәк, дип фаразлана.

Эшкә яраксызлык буенча пособиенең максималь күләме дә быел айга 122 мең сумнан артып китәчәк. Дөрес, моның өчен 8 ел һәм аннан да күбрәк эш стажы кирәк. 2024 елда 5–8 ел эш стажы булганнарга эшкә яраксызлык буенча пособиенең максималь күләме – 98 мең, 5 елга кадәр стаж булган очракта 74 мең сум.

Салым чигерүләре

Бу елдан түләп дәваланучыларга, түләп укучыларга каралган социаль «вычет» күләме артты. Озын сүзнең кыскасы, спорт, дәвалану, хәйриячелек, уку һәм иминиятләштерү өчен сарыф ителгән 150 мең сумга кадәр акчадан салым чигерергә мөмкин. Бу очракта 19500 сумга кадәр акча кире кайта. Ә бер баланы көндезге бүлектә укыткан өчен 110 мең сумга кадәр акчадан «вычет» алырга була, алдагы ел белән чагыштырганда бу ике тапкыр күбрәк. Әти-әниләр түләгәннең 14300 сумын кире кайтарырга мөмкин.

Салым дигәннән, былтыр ил күләмендә күчемсез милекнең кадастр бәясен дә яңадан исәпләделәр. Кайбер мәгълүматларга караганда, әлеге төр салым 21 процентка кадәр артырга мөмкин. Тик яңа бәяләрне агымдагы ел өчен салым исәпләгәндә генә файдаланачаклар.

Яңа мая

Бу елдан илдә озак вакытка исәпләнгән акча саклау программасы эшли башлады. Моның өчен дәүләтнеке булмаган Пенсия фонды белән килешү төзергә һәм шунда даими рәвештә акча күчереп барырга кирәк. Программада 18 яшьтән тәләге булган һәркем катнаша ала. Килешү төзегәндә, беренчел кертем күләмен, аның вакытын һәм суммасын үзең билгелисең. Тик шунысы бар: килешү ким дигәндә 15 елга төзелә. Ягъни түләүләр әнә шул вакыттан соң гына яки хатын-кызларга – 55, ир-атларга 60 яшь тулгач килә башлаячак. 2,8 миллион сумга кадәр җыелган акча иминиятләштерeләчәк. Мая, иң беренче чиратта, фондка даими кертемнәрдән җыелачак. Шулай ук, программага пенсиянең 2014 елдан бирле «катырылган» тупланма өлешен дә күчерергә рөхсәт ителәр.

Белгеч сүзе

«Кредит бик кирәкмәсә, аны алмавың хәерле»

Финанс үзгәрешләренә бәйле вазгыять турында Татарстан Иҗтимагый палатасының финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча белгече Фәнис ХӨСӘЕНОВ белән сөйләштек.

:: Акча мәсьәләсендә 2023 елниләр белән истә калды?

– Узган елның иң истә калган вакыйгасы – күпчелек халыкның, бигрәк тә эшчеләрнең хезмәт хаклары артты. Тик финанс грамоталылыгы җитмәү аркасында, бу бәйрәм алга таба да дәвам итәчәк, дип уйладылар, ахры. Халык күпләп кредит рәсмиләштерергә һәм чит ил товарлары сатып алырга тотынды. Аңлашыла ки, илдә бу кадәр импорт юк. Шуңа күрә ул бәяләр үсүгә китерде. Икенчедән, халыкның кредит «йөге» бик нык артты. Ипотека мәсьәләсендә бигрәк тә. Бүген халыкның банкларга булган бурычының яртысы нәкъ менә ипотека түләүләренә туры килә. Һәм әлеге хәл соңгы ике елда нык күзәтелә. Сорау арткач, торак бәясе дә югары сикерде. 1 гыйнвардан беренчел кертем күләме арту әлеге базарны бераз суытыр дип өметләнәбез. Дөрес, Үзәк банк гамәлгә керткән үзгәрешләрнең беренче нәтиҗәләре елның икенче яртысында гына күренәчәк.

:: Бу ел нинди яңалыклар алып килде?

– Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме арту нәтиҗәсендә, балалар пособиеләре, «больничный» акчасы, эшсезлек буенча пособие кебек МРОТка бәйле булган барлык төр түләүләр үсәчәк. Пенсионерлар да акчаны күбрәк алачак. Ә ана капиталына бәйле үзгәреш мигрантларга әлеге төр матди ярдәмне алу хокукын чикли. Иң мөһим яңалыкларның берсе ипотекага бәйле. Белгәнебезчә, 1 гыйнвардан беренчел кертем күләмен 30 процентка кадәр арттырдылар. Бу – бүген илдә гамәлдә булган барлык ташламалы программаларга да кагыла. Хәзер фатир бәяләре болай да бик кыйммәт булуны исәпкә алганда, күпчелек гаиләләр өчен беренчел кертемне җыю хәлдән килмәстәй эшкә әверелергә ихтимал. Тагын шунысы да бар: быелдан банклар һәм микрофинанс оешмалары, кредит рәсмиләштергәнче, бурычка акча алучының чыгымнарын исәпләргә мәҗбүр булачак. Әгәр айлык түләүләр хезмәт хакының яртысыннан да артыгын тәшкил итә икән, бу очракта кредит алучы түләүгә бәйле куркынычлар турындагы махсус документ имзаларга тиеш. Җаваплылыкны үз өстенә ала, кыскасы.

:: Акча тотуга бәйле нинди киңәш бирер идегез?

– 2023 елда төп ставканы бер ел эчендә ике тапкырдан да күбрәккә арттырдылар. Хәзер ул 16 процент тәшкил итә. Аңлашыла ки, бу халык арасында кредитлар алу хисабына акча тотуны киметү өчен дә эшләнде. Бүген банклар куллану кредитын, мәсәлән, 16–18 процент белән бирә. Тагын да шул белем җитмәү: кайберәүләр, бүген кредитны югары процент белән алам да, алга таба төп ставка төшкәч, бурычны рефинансларым, дип уйлый. Болай фикер йөртүчеләрне Үзәк банк башлыгы алдан ук кисәтте: югары ставкалар әле озак сакланачак. Шуңа күрә бүгенге шартларда кредит бик кирәкми икән, аны алмавың хәерлерәк. Чөнки бурычларыгыз күтәрә алмаслык йөккә әйләнергә мөмкин. Быел хезмәт хаклары былтыргы кебек күпкә артмаячак. Ник дисәң, күп кенә оешмалар моңа бәйле үз мөмкинлекләрен кулланып бетерде инде.

АЛМАЗ ХИСАМЕТДИНОВ:

«ВЕТЕРИНАРИЯДӘ ГАДИ ЕЛ ЮК»

Ветеринарларга уяулыкны тагын да көчәйтергә, хуҗалыкларга билләрне кысыбрак буарга туры киләчәк. Башка чара юк, чөнки терлекләр арасында онытылган авырулар да баш калкыта, яңалары да өстәлә тора.

Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы Алмаз ХИСАМЕТДИНОВ белән узган елга нәтиҗә ясадык һәм быелга планнарны барладык.

:: Алмаз Габдерәүфович, узып киткән ел ветеринарлар өчен шактый сынаулы һәм мәшәкатьле булды. Үзегез өчен нинди төп вакыйгаларны билгеләп узар идегез?

– Ветеринария хезмәте өчен бер елның да гади генә булганы юк. Һәр ел үз мәшәкате, авырулары белән килә. Иң элек минем уңай якларга тукталасым килә. 2023 елда котыру авыруының, дуңгызларда Африка чумасының бер генә очрагы да булмады. Әмма көтелмәгән башка авырулар килеп чыкты. Һич уйламаган җирдән, якын-тирә территорияләрдә булмаган вакытта Лениногорск шәһәрендәге кош фабрикасында кош гриппы ачыкланды. Нәтиҗәдә йомырка юнәлеше буенча эшли торган кошчылык фабрикасын ябарга туры килде. Икенчесе – бруцеллез авыруы. Мөгезле эре терлекләр арасында бу авыруның республикада күп еллардан бирле булганы юк иде. Авыру безне бөтен яклап камап алса да, аны биш ел кертмичә, республиканы саклап килә алдык. Кызганыч, быел әлеге куркыныч авыру Яңа Чишмә һәм Әтнә районнарына үтеп керде.

:: Сез телгә алган һәр очрак – республика өчен зур югалту һәм сынау. Авыруларның килеп чыгу сәбәпләре ачыкландымы, чылбыр төзелдеме, гаеплеләр билгеле булдымы? Бу хәлләрдән без нинди сабак алдык?

– Узган ел булган бер генә очракка да әлегә нокта куелмаган, чөнки тиешле органнар бу мәсьәлә буенча тикшерү эшләре алып бара. Шуңа күрә бүген гаепләләрне әйтергә иртәрәк. Ә алар табылачак, әлбәттә. Авыру сәбәпләре күп төрле булырга мөмкин. Кайсыдыр объектыбызга йогышлы авыру килеп кергән икән, андый очракларның 90 процентында кеше гаепле. Әгәр без биологик сакланышны тиешенчә үтәсәк, хуҗалыкларга авыру килеп кермәс иде. Кайдадыр читтән транспорт, ят кешеләр, хезмәт күрсәтүчеләр керә. Алар фермаларга бары тик дезинфекцияләү барьеры һәм санитар эшкәртү узып кына керергә тиеш. Гомумән, территориядә эшли торган техника аерым булу хәерле. Кеше генә түгел, кошлар да авыру тарата ала. Ләкин безнең өчен иң куркынычы – читтән алып кайткан терлек. Тикшерелмәгән малларның күпчелеге шәхси хуҗалыкларга кайта. Эшмәкәрләрнең 90 проценты безнең белән элемтәдә булса да, кызганыч, алар арасында да кача-поса алып кайтучылар бар. Каяндыр алып кайткан һәр малның бөтен мәгълүматы язылган ветеринария документы булырга тиеш.

:: Бруцеллез кешеләр өчен дә куркыныч булуы белән катлаулы. Авыру ачыкланган хуҗалыкларда эшләүчеләрнең хәле ничек? Аларны тикшерделәрме? Авыручылар бармы?

– Авыру ачыкланган хуҗалыкларда эшләүчеләрне Роспотребнадзор идарәсе белгечләре тикшерде. Ләкин кешенең сәламәтлегенә бәйле нәтиҗәләрне безгә әйтмиләр, чөнки ул табиб сере булып санала.

:: Кайчандыр булып, аннары онытылган авыруларның кабат баш калкытуын сез ничек аңлатасыз?

– Төгәл сәбәбен әйтә алмыйм, ләкин кешеләр арасындагы вируслар да гел үзгәреп тора бит. Бу табигать шартларына да бәйле булырга мөмкин, чөнки климат җылына, ә мондый шартларда микроблар күбрәк һәм тизрәк үрчи.

:: Алардан ничек сакланырга? Республикада нинди профилактика чаралары уздырыла? Быел яңа саклану чаралары кертеләчәкме?

– Гомумән алганда, без елны үзебезнең бурычларны үтәп төгәлләдек. Мал табибларының эше елдан-ел арта, чөнки авыруларның искеләре баш күтәрде, яңалары барлыкка килде. Мөгезле эре терлекләрдә генә түгел, сарык һәм кәҗәләр, кошлар арасында да яңа авырулар бар. Аларга каршы профилактика чараларын эшләп барабыз, ләкин барысыннан да саклану чаралары юк. Әйтик, дуңгызларда Африка чумасына каршы вакцина юк. Кош гриппының да эшли торган, сыйфатлы вакцинасы уйлап табылмаган. Бруцеллез белән дә шушы ук хәл. Безнең республика 30 елдан артык бу авырудан азат булганлыктан, вакцина салуның кирәге дә юк иде. Әйткәнемчә, аның сыйфатлы вакцинасы да юк. Шушы ике очрактан соң без әлеге мәсьәлә буенча ныклап шөгыльләнәчәкбез, ләкин бу тиз генә башкарыла һәм бездән генә тора торган эшләр түгел. Шуңа күрә быел бу авыруга каршы прививка булмаячак.

:: Кошчылык һәм дуңгызчылык комплекслары йогышлы, тиз тарала торган авырулардан яхшырак сакланган шикелле. Мөгезле эре терлек фермалары, комплекслары турында алай дип әйтеп булмый. Узган ел ахырында аларны ябык режимга күчерү буенча сөйләшүләр алып бара башладылар. Шул турыда да аңлатып узыгызчы.

– Без кош һәм дуңгыз предприятиеләрен ябык режимга күчерү буенча 20 еллап шөгыльләнәбез, чөнки алар арасында авырулар алданрак чыкты. Шуңа күрә аларның күпчелегендә тиешле таләпләр үтәлгән. Ә менә мөгезле эре терлек белән эшли торган

Илдар Мөхәммәтҗанов

предприятиеләрнең барысы да ачык. Яңа төзелгән комплекслар арасында да үрнәк итеп куярлыкларын әйтә алмыйм. Моңарчы алар арасында андый йогышлы авырулар булмау сәбәпле, дәүләт тарафыннан да, бездән дә катгый таләпләр куелмады. Бүген авырулар күбәйде, алар тиз тарала. Шуңа күрә безнең алга Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та, министр Марат Җәббаров та республика предприятиеләрен ябык режимга күчерү бурычын куйды. Бу – чагыштырмача кыйммәтле эш, әмма аны башкармыйча булмый. Гади генә әйткәндә, төп өч бурыч куела: территорияне коймалап алу, дезинфекцияләү барьерын һәм санитар үткәрүне тәэмин итү. Шушыларны үтәгән очракта, без предприятиене тышкы факторлардан арындырабыз.

:: Ветеринария ягыннан карасак, хуҗалык итүнең кайсы формасы уңышлырак дип саныйсыз: эре агрохолдинглармы, әллә фермер хуҗалыкларымы?

– Бәлки минем белән килешмәүчеләр дә булыр, әмма хуҗалык ул артык зур булырга тиеш түгел, чөнки авырулар йоктыру куркынычы бүген бик зур. Элек фермаларда 1000–1200 баш терлек асрала иде. Ә бүген без 6 мең баш сыерга зур комплекслар төзибез. Әлбәттә, бу экономия, җитештерү ягыннан файдалыдыр, тик ветеринария ягыннан караганда дөрес түгел. Без үз киңәшләребезне бирәбез, тик күпчелеге аларга бармак аша гына карый. Бер урынга бик күп терлекне җыю дөрес түгел. Ниндидер авыру килеп чыккан очракта, аларның барысын да юк итәргә туры киләчәк.

:: Сез эшләү барышында малларда лейкоз буенча шактый уңышлы күрсәткечләргә ирештегез. Тик соңгы вакытларда хуҗалыкларда әлеге авыруны еш телгә ала башлады. Бүген аның буенча вазгыять ничек?

– Лейкозга игътибар арту кабул ителә торган сөтнең сыйфатына таләпләр көчәюгә бәйле. Җәен сөткә ихтыяҗ кимеде, бәясе төште. Бу исә үз чиратында сыйфатка игътибарны арттырды. Без дә лейкоз белән ныклап шөгыльләнәбез. Бүген хуҗалыклардагы терлекләрнең 1,7 процентында әлеге авыру бар. Ун ел элек бу күрсәткеч 30 процент иде. Авыру терлекләр башлыча фермер һәм шәхси хуҗалыкларда асрала. Бу мәсьәләдә безгә вак хуҗалыклар бетеп, эре комплекслар килү дә ярдәм итте. Моннан тыш, лейкозга федераль таләпләр дә йомшак иде. Бүген Лениногорск, Яңа Чишмә, Спас, Чирмешән, Лаеш, Кама Тамагы районнары терлекләренең лейкоз авыруы белән бөтенләй шөгыльләнмәгәннәр. Аларда авыру терлекләр 10 проценттан артык. Болар – терлекчелеккә бармак аша гына караучы районнар. Киләчәктә әлеге авыруга каршы федераль таләпләр тагын да артачак. Авыру сыердан савып алынган сөтнең бәясе шушы 1–2 ел эчендә бөтенләй башка бәядән йөреячәк, шуңа күрә моңа әзер булып торырга кирәк. Соңгы елларда бу мәсьәләдә Тукай, Алабуга, Теләче, Зәй, Сарман, Кайбыч районнары, зур көч куеп, авырудан чистарып бетте. Балтач, Әтнә, Арча, Саба районнары болай да лейкоздан чиста районнар санала.

:: Узган ел ветеринарлар башкарган зур эш турында да әйтми калу дөрес булмас. Алар терлекләрне исәпкә алдылар һәм идентификацияләделәр. Куелган максатларга ирештегезме?

– Узган ел ветеринария хезмәткәрләре шәхси хуҗалыклардагы малларны – тулысынча, җитештерү предприятиеләрендәгеләрнең 80 процентын учетка алды. Закон үз көченә быел 1 марттан керә. Һәм без 1 сентябрьгә барлык төр терлекне дә исәпкә алып бетерергә тиеш. Бу вакыттан хуҗалыкларга җитди таләпләр куелачак, чөнки системага кермәгән терлекнең үзен дә, продукциясен дә сатып булмаячак, документ та, субсидия дә бирелмәячәк.

:: Яңа аяк баскан елдан нәрсә көтәсез?

– Безнең хезмәттә алдан планлаштырып булмый. Без алдагы елда түгел, иртәгә нәрсә буласын да белмибез, чөнки республика бик күпкырлы, терлекләребез күп, йогышлы авырулар килеп чыгу куркынычы бик зур. Шуңа күрә зур фаразлар ясау мөмкин түгел. Әлбәттә инде, имин, тыныч еллар телибез. Авырулар азрак, җитештергән продукциябез күбрәк һәм сыйфатлырак булсын иде.

Әңгәмәдәш – Зөһрә САДЫЙКОВА

Чулпан
ГАРИФУЛЛИНА

КЕШЕ АШЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Рәхәт яшибез, җәмәгать. Кибеттә, плитә алдында үткәрә торган вакытны янга калдырам дисәң, курьерларга бер сызгыру да җитә. Шәһәрдәгеләр шуңа күнегеп бара инде.

Аяк ардырып йөрисе дә юк, ризык хәзер үзе «килә». Өйгә ризык, азык-төлек китертү шәһәр халкы (хәтта кайбер районнарда да) өчен көннән-көн табигый күренешкә әйләнеп бара. Бу хезмәткә ихтыяҗ ни өчен зур? Китереп бирү хезмәтеннән күбрәк кемнәр файдалана? Шул сорауларга җавап эзләдек.

Вакыт кадере

Казанның 7 нче шәһәр клиник хастаханәсендә эшләүче медицина хезмәткәре Искәндәр Нурмиев китереп бирү хезмәтеннән бик теләп файдалана. Әмма җиләк-җимеш, яшелчә сатып алу өчен кибетләргә, махсус сату нокталарына йөри икән.

– 2–3 ел инде кибетләрдә продукция эзләп йөргәнем юктыр. Бәхәссез, бәяләре бераз гына кыйммәтрәк булса да, китереп бирү хезмәте кеше өчен кадерле вакытны янга калдырырга булышуы белән отышлы. Чиратта да тормыйсың. Әзер ризыклар сыйфатлы була, җылытып алдың да ашадың, бик җайлы. Ә менә җиләк-җимеш, яшелчәләрне кибетләрдән китертмим, махсус сайлап, тәмләп карап сатып алырга яратам. Ит, йомырка кебек нәрсәләрне дә кибеттән алмыйм, авылдан алып киләм, – ди ул. – Тизлеге, сайлау мөмкинлеге зур булуы белән отышлы ул китереп бирү хезмәтләре. XXI гасырда онлайн сәүдә һәркем өчен актуаль. Коронавирус чорында алар популярлык казанды һәм шул популярлыкны югалтмый.

Башкала читендәге Константиновка бистәсендә яшәүче өч бала анасы Диләрә Гыйбадуллина да өйгә азык-төлек китереп бирү хезмәтен бик хуп күрә.

– Машинада йөри белсәм дә, өч бала белән иркенләп азык-төлек кибетләренә чыгам димә. Эштән арып кайта торган иремә дә һәрвакыт мөрәҗәгать итеп булмый инде. Шуңа күрә айга 3–4 тапкыр өйгә китертү хезмәтеннән файдаланам. Кайчагында продукция күләме 25 килога да җитә. Бик ялкауланган вакытта, әзер ризык та китертәм. Моның аяты юк, – ди ул. – Хәзер вакытның һәркем өчен дә кадерле чагы. Ә азык-төлек бәяләре ничек «тешли»! Каядыр җыенып чыгып, бензин ягып йөрүеңне дә кушсаң, үзеңнең кадерле вакытыңны да өстәсәң, никадәр чыгымлы икәнен чамаларга була. Кибетләр төрле промокодлар, ташламалар тәкъдим итеп торганда, заказ биреп китертү күпкә отышлырак та чыга әле.

Ялкаулык та курьерларга мөрәҗәгать итү сәбәбе булырга мөмкин. Казанда яшәүче Алия Зиннурова шулай ди әнә. Әлегә ялгызы гына яшәүче кызның плитә янында басып торырга әллә ни теләге дә, вакыты да юк. Көндез белем эстәсә, кич эшли.

– Аларны чакырта-чакырта, тәҗрибә арткан саен, өйгә продукция китертүнең отышлы яклары да табыла. Әйтик, банк картасына бонуслар «тама», заказ биргәндә, ташламалы промокодлардан файдаланырга була. Аннан соң, бик-бик тәмле ризык ашыйсы килгәндә, аны әзер килеш китертү фәлән сумга продукция җыеп пешерүгә караганда очсызрак та, җайлырак та була бит. Тик бу кагыйдә күбрәк үзе генә яшәүчеләргә яки балалары булмаган гаиләләргә кагыладыр. Хәзер бит кафе-рестораннарда да курьер хезмәте популяр. Кыскасы, курьерларга да, китереп бирү хезмәтен уйлап чыгарган кешеләргә дә мең рәхмәт. Ялкауланган чакларда да, мең эш мең якка таралып яткан вакытларда да гел ярдәм итәләр. Алар тормышны җиңеләйтә.

Кибеттән – өйгә

Яна бик танылган азык-төлек һәм ризык китерү хезмәте курьеры булып эшли. «Кыз башың белән курьер булып эшлисеңме?» – дигән сорауны еш ишетә ул. Янәсе, эшмени бу? Янаның хезмәтенә карата фикере мондый:

– Мин эшемнең бары тик уңай якларын гына күрәм. Яратып башкарам, әйбәт итеп түлиләр дә әле өстәвенә. Безнең арада, бик беләсегез килсә, аниматор да, юрист та, фотограф та, фән кандидатлары да бар. Кайчан, ничә сәгать һәм кайда эшләвемне мин үзем сайлыйм. Җитәкчегә җайлашырга кирәкми, җомга аясә ялляр җиткәнен зарыгып көтмим. Үземә үзем хуҗа.

Сүз дә юк, курьер булып йөрүнең дә кыенлыклары җитәрлек.

– Физик яктан авыррак. Ерак йөрергә дә туры килә. Җәен самокат кулланам. Андый вакытта еш кына җәяүлеләргә дә, юлдагы машиналарга да сүгенеп куйгалыйм. Чөнки күп очракта алар да игътибарсызлык күрсәтә, кагыйдәләрне санга сукмый, бик тупас кылана, – ди Яна. – Сер түгел, курьер булып эшләвеннән оялучылар безнең арада да бар. Әмма мин андый түгел. Нинди эш тә – хезмәт.

«ГородРабот.ру» хезмәте мәгълүматларына ышансаң, Казан курьерларының уртача хезмәт хакы – аена 68 мең 593 сум. «Курьер кирәк» дигән вакансияләрдә исә иң еш очрый торган сан – 45 мең сум.

– Шул саннар арасында тирбәлә минем хезмәт хакы, – дип, сер йомгагын чишми калдырды Яна да.

Сан

• Россия күләмендә **2021 елда** китереп бирү эшендә **830 мең** кеше эшләгән булса, **2023 елда – 1 млн**.

• **2022 елда** Россиядә курьер хезмәтеннән файдаланучылар саны **24,5 процентка** арткан һәм **1,7 трлн сум** табыш китергән. Моңа өйгә кадәр азык-төлек һәм әзер ризык китертү хезмәтләре керә. **2023 ел** саннары да моннан ким булмас дигән фараз бар.

Фикер

Чулпан НИГЪМӘТҖАНОВА-ГАРӘФИЕВА, психолог, арт-терапевт:

– Психология күзлегеннән караганда, китереп бирү хезмәтенә ихтыяҗ артуны җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйләргә була. Кешенең фикерләү рәвеше, тормышка карашы, кеше үзе үзгәрә. Замана кешесе хәзерге көндә буш вакытын оптимальләштерергә омтыла. Ягъни буш вакытын үзенә кызыклы, керем, файда китерерлек эшкә сарыф итәргә тырыша. Вакытны янга калдыру мөмкинлеге булса, ул бу мөмкинлектән файдалана.

Кибеткә бару өчен җыенып чыгарга, продукция исемлеген төзергә, кибет буенча эзләнеп йөрергә, чиратта көтеп торырга, авыр сумкалар күтәреп өйгә кайтырга кирәк. Бу бик күп көч, энергия һәм вакытны ала. Ә бу төшенчәләрнең бәһасе хәзер бик зур. Элекке заманда төп кыйммәт булып физик хезмәт саналса, хәзер – вакыт. Хәзерге заманда физик хезмәтне алмаштыра аясә аны куллануны киметтергә мөмкинлек бирердәй хезмәтләр күп. Шул ук робот-тузан суырткыч, кер юу машинасы, дисеңме.

Азык-төлекне, ризыкны өйгә китерттерүче кем ул? Психологик күзлектән караганда, болар – гадәттә, интровертлар. Ягъни күбрәк үзләре генә булырга яратучылар, халык күп йөри торган урыннарда йөрергә яратмаучылар. Мондый төр хезмәттән файдалану бала ялында утыручы әниләргә дә хас. Үз бизнесы белән мәшгульләр, үзен үстерүгә (саморазвитие) күп вакыт бирүчеләр дә керә монда.

Продукцияне, ризыкны китереп бирү пандемия чорында популярлашты. Моңа кадәр, сер түгел, ул бу кадәр киң таралмаган иде бит. Кеше яхшыга тиз ияләшә.

8 гыйнвар | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

8.00 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК ИКӘН» 16+
10.00 «ЖАР-ПТИЦА» 0+
11.35 Мультфильмы 16+
12.00, 22.10 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ...» 16+
13.00 Р. Ваһапов исемендәге XX Халыкара татар җыры фестиваленең гала-концерты 16+
15.00 «Калеб» яңа буын җыенының 10 еллыгына багышланган бәйрәм чарасы 12+
17.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
18.00 Раяз Фасыйхов концерты 12+
18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Заман көзгесе» 6+
23.00 «Путешествие было приятным» 6+
00.25 «Каравай» 6+
00.50 «Путь» 16+
01.05 «Реквизиты былой суеты» 6+
01.20 «Семь дней +» 16+
01.45 «Татар халык җырлары» 0+
02.00 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
06.50 «Бәхетлеме син?» 16+
09.00, 05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 Р. Харис. «Күзләреңнән үбеп...» С. Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт театры спектакле 16+
12.05, 04.20 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
13.05, 23.30, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
14.00 И. Юзеев. «Ак калфагым төшердем кулдан...» Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
16.10 «Бу – димәк, мәхәббәт» 16+
18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
18.20 «Яңа татар җыры 2023» конкурсының гала-концерты 16+
20.40, 00.40 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
21.25 И. Зәйниев. «Люстра». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
01.05 «Манзара» 16+
03.05 «Әдәби хәзинә» 6+

1 КАНАЛ

06.00, 10.00, 12.00 Новости
06.10 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
06.55 «ФИНИСТ – ЯСНЫЙ СОКОЛ» 0+
08.25 «СТАРИК ХОТТАБЫЧ» 0+
10.15 «Наше всё» 0+
11.05 «Жизнь своих» 12+
12.15 «Повара на колесах» 12+
13.10 «Видели видео?» 0+
15.10 «Буруновбезразницы» 16+
16.20 «ОЛИВЬЕ» 16+
18.00 Вечерние новости
18.20 «Легенды «Ретро FM» 12+
21.00 «Время»
22.00 «ДОКТОР ПРЕОБРАЖЕНСКИЙ» 16+
23.00 «Вулкан Сергей Параджанов» 16+
23.40 «ТЕНИ ЗАБЫТЫХ ПРЕДКОВ» 16+
01.35 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

04.30 «АИСТ НА КРЫШЕ» 16+
08.00 Вести. Местное время
08.35 «Когда все дома»
09.25 «Утренняя почта»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 20.00 Вести
11.30 Международный турнир по художественной гимнастике «Небесная грация»
14.00 «ЧУЖАЯ СЕСТРА» 12+
17.50 «Песни от всей души» 12+
22.00 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
00.40 «КАНДАГАР» 16+
02.30 «ЕСЛИ БЫ Я ТЕБЯ ЛЮБИЛ...» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 Бокс. Bare Knuckle FC. Росен Димитров против Тодора Железкова 16+
07.00, 10.00, 12.50, 16.25, 03.55 Новости
07.05, 14.55, 18.30, 21.45 Все на Матч!
10.05 «Команда МАТЧ» 0+
10.30 «НА ПРЕДЕЛЕ: ИСТОРИЯ ЛЕГЕНДЫ» 12+
12.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Енисей» (Красноярский край) – УНИКС (Казань)
15.40, 00.15 Футбол. Кубок Испании 6+
16.30 Дартс. OLIMPBET Чемпионат профессиональной лиги
18.55 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Женщины. «Локомотив» (Калининградская область) – «Динамо» (Москва)
20.50 «Вы это видели» 12+
22.30 Наши в UFC 16+
01.00 «Что по спорту?» 12+
01.30 «Магия большого спорта. Шахматы» 12+
02.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Самара» – ЦСКА 6+
04.00 Бильярд. «BetBoom Суперлига» 1/2 финала 0+

НТВ

05.15 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.20 «НАСТОЯТЕЛЬ» 16+
10.20 Концерт Надежды Бабкиной и театра «Русская песня» 12+
12.15 «БАЛАБОЛ» 16+
19.25 «БИМ» 16+
22.15 «Мы верим твердо в героев спорта» 12+
23.50 «Земляне». Возвращение легенды» 12+
02.40 «СТАРЫЕ КАДРЫ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.35 «ТАРИФ НА ЛЮБОВЬ» 16+
08.15 «МОЛОДАЯ ЖЕНА» 16+
10.20 «МАЛЕНЬКАЯ ТАЙНА, БОЛЬШАЯ ЛОЖЬ» 16+
15.00 «КОМНАТА РОЗ» 16+
23.40 «СЕРДЦЕ ЖЕНЩИНЫ» 16+
01.45 «ПРИЕЗЖАЯ» 16+
03.20 «Знать будущее. Жизнь после Ванги» 16+

ЗВЕЗДА

05.40 «СПАС ПОД БЕРЕЗАМИ» 16+
07.10 «ОТЧИЙ ДОМ» 12+
09.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15 «Война миров» 16+
15.00, 19.15 «Скрытые угрозы» 16+
21.00 «НАЙТИ И ОБЕЗВРЕДИТЬ» 16+
22.50 «КЛУБ САМОУБИЙЦ, ИЛИ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ТИТУЛОВАННОЙ ОСОБЫ» 12+
02.10 «КОРАБЛИ ШТУРМУЮТ БАСТИОНЫ» 12+
03.45 «СМЕРШ. ЛЕГЕНДА ДЛЯ ПРЕДАТЕЛЯ» 16+

9 гыйнвар | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.15, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 18.45 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «ТУЗГАН ТОРАКТАН КҮЧКӘНДӘ» 16+
11.00, 01.05 «Фолиант в столетнем переплете» 16+
11.15, 00.25 «Если хочешь быть здоровым» 16+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ...» 16+
13.00, 00.40 «Соотечественники» 16+
13.30 «Каравай» 6+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Семь дней +» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.30 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 16+
17.30 «Дуслык иленде» 12+
17.45, 01.35 «Таяну ноктасы» 16+
19.15 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Барыс» 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.00 «БРИЛЛИАНТЫ ДЛЯ ДЖУЛЬЕТТЫ» 12+
00.00 «Видеоспорт» 16+
01.20 «В стране дружбы» 12+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Кәмит Җавит» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 18.20, 23.10, 04.20 «Җырлыйк әле!» 16+
09.30, 17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
10.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
10.30 «Ватандашлар» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Ике аккош» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ДОКТОР ПРЕОБРАЖЕНСКИЙ» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 «ЦВЕТ ГРАНАТА» 12+
01.35 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 12+
23.30 «САМА ВИНОВАТА?» 18+
01.00 «СКАЖИ ПРАВДУ» 12+
03.30 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Лига в лицах» 12+
06.30 «География спорта» 12+
07.00, 10.00, 12.50, 16.20, 03.55 Новости
07.05, 15.20, 21.45 Все на Матч!
10.05 «Лица страны» 12+
10.25 «24-часовая гонка» 12+
12.30 Специальный репортаж 12+
12.55 Смешанные единоборства. АСА. Эдуард Вартанян против Артёма Резникова 16+
13.55 «Один за всех» 16+
16.25 «Что за спорт?» 12+
16.55 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Металлург» (Магнитогорск) – «Локомотив» (Ярославль)
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. ЦСКА – «Торпедо» (Нижний Новгород)
22.30 Дартс. OLIMPBET Чемпионат профессиональной лиги
01.00 «Здоровый образ» 12+
01.30 «Магия большого спорта» 12+
02.00 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Локомотив» (Новосибирск) – «Нефтяник» (Оренбург) 6+
04.00 Бильярд. «BetBoom Суперлига». 1/2 финала

НТВ

08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «БАЛАБОЛ» 16+
16.45 «ДНК» 16+
20.00 «БИМ» 16+
23.20 «Смехополис» 16+
00.40 «ЛЕГЕНДА ФЕРРАРИ» 16+
04.40 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30, 05.45 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.30, 04.55 «Давай разведёмся!» 16+
08.30, 03.15 «Тест на отцовство» 16+
10.45, 23.40 «Понять. Простить» 16+
12.00, 00.55 «Порча» 16+
13.10, 01.55 «Знахарка» 16+
13.45, 02.20 «Верну любимого» 16+
14.20, 02.50 «Голоса ушедших душ» 16+
14.55 «ПЕРВОКУРСНИЦА» 16+
19.00 «О ЧЁМ ОНА МОЛЧИТ» 16+

ЗВЕЗДА

07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 18.50 «Специальный репортаж» 16+
11.35, 13.25 «ПОКРОВСКИЕ ВОРОТА» 12+
14.45, 17.15, 03.50 «ВЫСШИЙ ПИЛОТАЖ» 16+
15.00 Военные новости 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Улика из прошлого» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ГДЕ 042?» 12+
00.40 «НАЙТИ И ОБЕЗВРЕДИТЬ» 16+
02.05 «ЗАСТАВА В ГОРАХ» 12+

ТАШЛАМАЛАР һәм ГАРАНТИЯЛӘР HEROES.TATAR 117

- РОССИЯ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ ХИСАБЫНА ТУПЛАНМА-ИПОТЕКА СИСТЕМАСЫ АША ТИЗ АРАДА ТОРАК САТЫП АЛУ МӨМКИНЛЕГЕ
- ХЕЗМӘТ УРЫНЫННАН ТОРАК ЯКИ ТОРАКНЫ НАЙМГА АЛЫП ТОРГАН ӨЧЕН КОМПЕНСАЦИЯ
- ХӘРБИ-МЕДИЦИНА УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ БУШЛАЙ ТИКШЕРЕНУ, ДӘВАЛАНУ һӘМ РЕАБИЛИТАЦИЯ УЗУ
- ФЕДЕРАЛЬ БЮДЖЕТ ХИСАБЫНА ГОМЕРНЕ һӘМ СӘЛАМӘТЛЕКНЕ ИМИНИЯТЛӘШТЕРҮ
- 20 ЕЛ ХЕЗМӘТ ИТКӘННӘН СОҢ ТАШЛАМАЛЫ ПЕНСИЯ АЛУ ХОКУКЛАРЫ
- ХӘРБИ ХӘРӘКӘТЛӘР ВЕТЕРАНЫ СТАТУСЫ һӘМ ТИЕШЛЕ ТАШЛАМАЛАР
- КРЕДИТ һӘМ САЛЫМ КАНИКУЛЛАРЫ
- БАЛАЛАРНЫ ВУЗДА БУШЛАЙ УКЫТУ
- БАЛАЛАРГА ҖӘЙГЕ САВЫКТЫРУ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА БУШЛАЙ ЯЛ
- КОНТРАКТ БУЕНЧА ХЕЗМӘТ ИТҮЧЕ ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫННАН БЕРДӘМ ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮЛӘР, ТАШЛАМАЛАР һӘМ ГАРАНТИЯЛӘР

ҺАЙ, ТАМАГЫМ!

Тамак авырта! Вируслы авырулар баш калкыткан чорда бу сүзләрне аеруча еш ишетергә туры килә. Араларында иң еш очрый торганы – ангина. Ул башка төр тамак авыруларыннан нәрсәсе белән аерыла? Ангинаны алдан кисәтү өчен нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк?

Табиб-оториноларинголог Айгөл ГАЗИЗОВА шул сорауларыбызга ачыклык кертте.

Күпләр ангинаны сезонлы авыру дип саный. Әмма бу – ялгыш фикер. Ангина белән елның теләсә кайсы фасылында авырырга мөмкин. Ангина, нигездә, туңганнан соң борчый башлый. Утәли җилдә йөрү, кондиционер астында утырганда туңу гына түгел, хәтта туңдырма ашагач, йә булмаса, салкын су, сөт эчү аркасында да пәйда була ала ул. Ангина белән өлкәннәр дә, балалар да бер үк дәрәҗәдә авырый. Иммунитеты какшаган, ВИЧ-инфекцияле кешеләргә аеруча сак булырга кирәк. Алар бу авыруга аеруча тиз бирешә.

Ангина белән авырганда тән температурасы 38 градуска кадәр күтәрелә, хәлсезлек сизелә, ашап булмый, аппетит югала, җылы су яки чәй эчсәң дә, тамак авыртуы басылмый. Авызны ачып, тамакны карагач, миндальсыман бизләрдә ак таплар күренә.

Ангинага бармак аша карарга ярамый. Аны вакытында дәваламасаң, миндальсыман биз үпкәләргә, хәтта кан агуланырга мөмкин. Ангинаны азындыру аркасында кеше гомере өзелгән очраклар да шактый. Йогышлы, хәтәр авыру бу. Ангина белән авырый башлаган кеше әйләнә-тирәдәгеләр өчен дә куркыныч тудыра. Андый кешенең бигрәк тә кечкенә балалар янынннан ерак торуы зарур.

Ангина кальян, тәмәке тартканда да йога ала дигән фикер яши. Әмма бу сүзләр дөреслеккә туры килми. Әлеге начар гадәтләр белән мавыгучылар күбрәк фарингиттан (йоткылыкның лайлалы тышчасы ялкынсыну. – **Ред.**) интегә.

Ангинаны үз белдеклегең белән теләсә ничек дәваларга да ярамый. Иң элек нәрсә аркасында (бактерия, вирус, гөмбәчек) пәйда булганлыгын ачыкларга кирәк. Шуннан соң гына ангинаны дәвалауга керешергә мөмкин. Тамак авырту өч көннән соң да бетмәсә, лор-табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Ангинаны тамакны чайкатып кына да җиңеп булмый, антибиотик эчә башларгамы икәнлеген фәкать белгеч кенә ачыклый ала.

Белеп тор!

ИНГАЛЯЦИЯ ЯСАУ ТЫЕЛА!

Тамак авыртуның беренче билгеләре сизелүгә үк, күпләр ингаляция ясау белән мавыга. Бәрәңге парын сулаучылар да очрый. Әмма тамак шешкәндә пар ингаляцияләре ясарга ярамый, дип кисәтә белгечләр. Җылылык аркасында шешү көчәя һәм кешенең тыны бетәргә мөмкин. Шулай ук тән температурасы 37,5 градустан югары булганда да ингаляцияләр ясарга ярамый, ул да ялкынсынуны арттыра.

vk.com

Ангинадан саклану өчен

- Ангинадан тилмергән кеше тамагын сакларга тиеш. Артык салкын ризык кына түгел, кайчак хәтта кайнар ризык та ангина китереп чыгарырга мөмкин. Ник дигәндә, йоткылыкның лайлалы тышчасы пешкәч, тамакка инфекция үтеп керә.
- Ангина вакытында сохари кебек каты, артык кайнар, ачы ризыклар ашаудан да тыелырга кирәк.
- Туңу, салкын тиюләрдән дә саклану зарур. Ник дигәндә, ангина салкын тигәндә ахырга чаклы дәваланып бетмәү аркасында да пәйда була.
- Бүлмәне даими рәвештә җилләтеп тору, организмны чыныктыру да ангинаны кисәтергә ярдәм итә.

Саклап куй!

Тамак чайкау

Чөгендер суы. Иң элек вак тишекле угычта уылган чөгендернең суын чыгарырга кирәк. 1 стакан чөгендер суына 1 аш кашыгы серкә (эссенциясен түгел!) өстәп, көненә 5–6 тапкыр тамакны чайкыйсы.

Сарымсак төнәтмәсе. Чистартылган һәм вакланган 100 г сарымсакка бүлмә температурасындагы 100 мл кайнаган су салып, өстен томалап, 5–6 сәгать тотарга кирәк. Шуннан соң аны сөзеп, җылымса көенчә тамакны чайкыйсы.

Киңәш-табыш

ЧӘЙ ЭЧӘБЕЗ БАЛ БЕЛӘН

➤ **Кара чәй** иммунитетны ныгыта, нерв системасы эшчәнлеген яхшырта. Даими рәвештә кара чәй эчкән кеше холестериннан котыла. Кара чәй составында витаминнар, минераллар, эфир майлары, кофеин бар. Чәй составындагы кофеин каһвәдәгесенә караганда да файдалырак. Ул йомшак кына тәэсир итә, ашказанату системасын, йөрәк эшчәнлеген яхшырта. Көнгә 5 чынаяк кара чәй эчү инсульт куркынычын 70 процентка киметә, дип ышандыра белгечләр.

➤ **Яшел чәй** кәефне яхшырта, бактерияләрне үтерә, организмнан кургаш, терекөмеш, цинк кебек авыр металларны чыгара һәм хәтта яман шешкә каршы да иң яхшы чара булып тора. Аның составында витаминнар, минераллар, антиоксидантлар күп. Яшел чәй артаны акрыкайта, иммунитетны ныгыта, матдәләр алмашын, баш мие эшчәнлеген яхшырта, кандагы шикәр күләмен нормага сала, югары кан басымын төшерә. Яшел чәйне 90 градуслы суда 5 минут пешерергә киңәш итәлә. Болай ул файдалырак була.

➤ **Ак чәй** – ак төк белән капланган чәй бөреләре. Аны яз башында җыялар. Чәйнең бу төре иммунитеты какшаган, хроник арыганлыктан интеккән кешеләргә киңәш итәлә.

➤ **Кызыл чәй** – чәй куагының иң өске яфраклары. Ул иммунитетны ныгыта һәм кан басымы түбән булганда киңәш итәлә.

Солы булыша

Солы ярмасы йөрәк-кан тамырлары һәм нерв системасына файдалы, организмда матдәләр алмашын яхшырта. Ревматизм, буыннар авыртуыннан да шифасы зур аның.

Ашказаны-эчәк авырулары вакытында. 1 стакан солыны 6–8 мәртәбә юарга, шуңа 2 стакан су салып кайнатырга. Су яртылаш кайнап беткәч, 2 аш кашыгы бал салып, тагын берничә минут кайнатырга. Катнашманы көнгә 2–3 мәртәбә ашар алдыннан эчәргә кирәк.

Диабеттан. 100 г солы орлыгына 3 стакан кайнар су салып, 8 сәгать төнәтәсе. Шуны көнгә 3–4 мәртәбә яртышар стакан эчәргә кирәк.

Бөер һәм сидек куыгы борчыганда. Бер стакан солы ярмасына 1 л кайнар су салып кайнатырга кирәк. Суның яртысы кайнап бетәргә тиеш, аннан аны сөзәсе булачак. Шуңа 2 стакан сөт өстәп, 20 минут кайнатырга кирәк. Көнгә 3 мәртәбә, ашар алдыннан 1әр стакан эчәсе.

Буыннарга тоз утырганда һәм авыртканда. Бер аш кашыгы солы орлыгын 1 л кайнар суга салып, 2 сәгать тотарга, аннан сөзәргә. Әлеге төнәтмәне бер ай буе көнгә 3 мәртәбә, ашарга ярты сәгать кала яртышар стакан эчәргә кирәк.

Склероздан. 1 стакан солы ярмасына 1 литр кайнар су салып кайнатырга, күләме яртылаш кимегәч, сөзәргә һәм шуңа 2 стакан сөт өстәргә кирәк. Шуны көнгә 3 мәртәбә, ашар алдыннан 1 стакан эчәргә.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

ХУШБУЙ ХИКМӘТЕ

vk.com

Кышын гүзәл затларга мамык шәл кебек җылы, «йомшак» исләр килешә. Суык чор өчен нинди исләр сайларга соң? Матурлык дөньясы белгечләре хушбуй алганчы түбәндәге киңәшләргә колак салырга куша.

ВАНИЛЬ. Күпләрне мөкиббән итә торган иң популяр исләрнең берсе. Бу татлы ис кыш өчен дә, җәй өчен дә кулай булган бик күп хушбуйларга хас. Ваниль исен танымый мөмкин түгел. Ләкин аны чамадан тыш кулланырга кирәкми, юкса сездән «кыйммәтле» ис урынына яңа пешеп чыккан күмәч исе килеп торачак.

АЛСУ БОРЫЧ. Хатын-кызлар хушбуена өстәлгән бу тәмләткечнең исе – салкынча агач исе белән яңа гына сабагыннан өзеп алган җимеш-неке арасындагы бер ис. Алсу борычның хуш исе кышкы сүлпәнлектән, битарафлыктан дәвалый торган тәмле бер даруныкына тартым.

МИЛӘҮШӘ ЧӘЧӘГЕ. Чәчәк исен яратсагыз, миләүшә чәчәгенекен (фиалка) сайлагыз. Татлы ис суыкта ниндидер бер җылылык, уңайлылык өсти. Миләүшәгә роза, әнис, канәфер исләре дә өстәлгән булырга мөмкин. Мондый хушбуй ирексездән яшьлекне искә төшерә.

КӨНЧЫГЫШ ТӘМЛӘТКЕЧЕ. Үзегездән соң хуш исләр (шлейф) калдырып китүне хуп күрсәгез, составында дарчин (корица), кардамон, канәфер, мөшкәт (мускат) чикләвеге, татлы тамыр (лакричник) булганын сайлагыз. Хушбуйга алар нәкъ менә кыш өчен бик кулай булган авыррак, әмма «кыйммәтле» ис өсти.

ИМБИР ҺӘМ БАЛ. Кышын иммунитетны ныгыту өчен кирәкле алыштыргысыз шушы ике ингредиент хәтта хушбуйда да кулланыла. Әмма икесе бергә бик сирәк кенә очрый. Имбир исе көчлерәк. Балныкы исә беленер-беленмәс генә.

ЛАДАН (ХУШ ИСЛЕ СУМАЛА). Хушбуйга җылылык, интимлык өсти. Ләкин авыррак ис, шуңа күрә кемнәргәдер ошамаска мөмкин.

Тәмле булсын!

ӘФЛИСУННАН – ВИТАМИНЛЫ МУСС

Римма Җамалиева рецепты

«Бәйрәм табынында тәмледән-тәмле ризыклар күп ашалды. Хәзер инде организмны җиңелчәрәк режимга көйләргә кирәк. Бу мусс нәкъ менә шуның өчен уйлап табылган кебек», – ди Римма.

***Кирәк:** 5 әфлисун, 200 грамм күрәгә, 1 стакан гадәти йогырт, тәменчә шикәр комы.*

Әфлисуннарны юып, кабыгыннан чистартабыз. Йомшагын иттарткыч аша чыгарабыз. Күрәгәне кайнар суга салып, 10 минут тотабыз да иттарткыч аша чыгарабыз (берничәсен бизәү өчен калдырабыз). Күрәгә һәм әфлисунны согы белән бергә салып болгатабыз. Йогыртка шикәр комы кушып күпертәбез. Стаканнарга (2 порция килеп чыга) күрәгә һәм әфлисун катнашмасын, өстенә йогырт салып, өстен күрәгә кисәкләре белән бизибез.

Укучы киңәше

Хәйләсе бар

Озакламый Яңа ел чыршысын «чишендерер» вакыт та җитәр. Шуны истә тотып, газета укучыларга берничә киңәш биреп үтмәкчемен. Мин үзем тиз ватылучан чыршы уенчыкларын бер тапкыр кулланыла торган пластик стаканнарга салып саклыйм. Уенчыклы стаканнарны капкачлы пластик тартмага урнаштырам да аулаграк урынга алып куям. Ә инде бик кечкенә уенчыкларны капкачлы йомырка савытына тутырам.

Чыршы гирляндасын исә кием элгечкә (плечик) чорнам куям. Болай ул беркайчан да чуалмый һәм чиямәнми.

Рәмзия САЛИХОВА.
Казан

Белеп тор!

КИРӘКМӘС БҮЛӘК

Яңа елга байтак кына бүләкләр җыелдымы? Тик арада күңелегезгә ятмаганнары да юк түгелдер. Бу очракта нишләргә?

✓ **Кибеткә кире кайтарырга.** Әйтик, иргез тузан суырткыч бүләк итте ди. Әмма сезгә башка төрлесе ошый. Кибеткә барып, аны үзегезгә ошаганына алыштырырга мөмкин.

✓ **Сатарга.** Хәзер белдерүләр сайтында теләсә нәрсәне сатып җибәрергә була.

Алыштырырга. Коллегагыз яисә берәр ахирәтегезгә дә кирәкмәс әйбер бүләк итми калмаганнардыр. Сезгә ошамаган аңа ошарга мөмкин бит. Әйтик, фәлән исле юыну геле. Сез аңа – шуны, ә ул алмашка башка әйбер бирәчәк. Социаль челтәрләрдә, форумнарда да кирәкмәс әйберләрне алыштыру төркемнәре бар.

✓ **Үзгәртергә.** Бүләк ителгән ниндидер кием ошамый икән, аны башка әйбергә үзгәртергә мөмкин. Мәсәлән, сезгә свитер бүләк иттеләр, ә ул сезгә ярамый (зур яки кечкенә). Аннан бик матур диван мендәрчеге яки үзенчәлекле кечкенә келәм ясагыз. Мичкә куеп пешерә торган сезгә ошамаган чүлмәкләр бүләк итсәләр, аны зәвыгыгыз буенча бизәп, гөл чүлмәге сыйфатында кулланырга була.

✓ **Бүләк итәргә.** Теләсә кайсы ярдәмгә шат булган гаиләләр бар. Мәсәлән, курткагызның төсенә туры килмәгән бияләйне яки кирәксенмәгән тәм-томлы тартманы шундыйларга бирергә мөмкин.

✓ **Призга әйләндерергә.** Карлы пыяла шарлар, ел символы сыннары кебек вак-төяк бүләкләр күп җыелса, күңелле уеннар белән балалар бәйрәме уздырыгыз. Мондый җирдә откан бүләккә балалар гына түгел, аларның әти-әниләре дә шат булачак!

Тәмле бәрәңге

Бәрәңгене төеп бетерер алдыннан йомырка агын күпертеп салсаң, боламык тәмлерәк булачак һәм күпереп китәчәк.

Дөге ак булыр

Дөге ярмасын пешергәндә, тәмлерәк булсын һәм аклыгын җуймасын өчен, суына бер тамчы алма серкәсе өстәгез. Яки пычак очына гына алып, лимон кислотасы өстәргә мөмкин.

Исеңдә тот!

Күн пирчәткәне яңарту

Күн пирчәткәне яңартып җибәрү өчен, кастор мае белән ышкып, сөңген көтәргә кирәк. Шулай ук күпертелгән йомырка сарысы белән дә ышкып карарга мөмкин. Пирчәтк күз алдында ялтырап, матурланып китәчәк.

Бәлзәмләү

Йон әйберне, юганнан соң, суга чәч бәлзәме салып чайкагыз. Болай эшләгәндә, кием ефәк кебек йомшаклыгын, нәфислеген җуймаячак.

АКТЫГЫ ҺӘМ АРТЫГЫ БУЛМАСЫН

Коръәндә: «Ашагыз, эчегез, ләкин исраф итмәгез. Чынлыкта Ул исраф итүчеләрне сөйми», – диелә. Чынлап та, кайчагында мул тормышына шөкер итәргә онытып, малны да, мөлкәтне дә, вакытны да кирәккә-кирәкмәсә исраф итәргә ярата адәм баласы. Нәрсә ул исраф? Вакытны ничек дөрес файдаланырга? Адәм баласы ни өчен Аллаһы Тәгалә биргән нигъмәтләрнең кадерен белми?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бу һәм башка сорауларга «Әл-Мәрҗани» мәчетеннән Ансар хәзрәт МИФТЯХОВ җавап бирде.

:: Исраф – нәрсә ул? Бу төшенчәгә аңлатма бирсәгез иде.

– Исраф – әйберне кирәгеннән артык куллану яисә кирәксә-кирәкмәсә дә куллану. Бу акчага да, вакытка да, Аллаһы Тәгаләдән бирелгән нигъмәтләргә дә, мал-мөлкәткә дә кагыла. Башкача әйтсәк, әрәм итү. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Һәрбер исраф кылу хәрамга китерә», – ди. Без бу хәрам гамәлдән тыелырга тиеш.

:: Кайдадыр кешеләр ризыкның кадерен белми, итне дә, сөтне дә, икмәкне дә чыгарып түгә, ә кайдадыр кешеләр чүп савытлары янында ризык эзләп, ачлыктан интегә. Раббыбыз тарафыннан бирелгән нигъмәтләрнең кадерен ник белмибез?

– Хәзерге вакытта мондый күренешләр очрый. Кайбер җирләрдә ризыкны ташлау бар, кайсыдыр урында бу ризыкка мохтаҗлык та бихисап. Дөньяда яшәгәндә үзебезнең ашаган ризыкны да, кигән киемне дә, гомеребезне дә, вакытыбызның да кадерен белергә тиешбез.

Коръәндә: «Ашагыз, эчегез, ләкин исраф итмәгез. Чын мәгънәсендә Аллаһы Тәгалә исраф итүчеләрне сөйми», – диелә. Кирәгеннән артыгын пешермәгез, кирәгеннән артыгын ашамагыз, кирәгеннән артыгын сатып алмагыз – Аллаһы Тәгалә безгә моны турыдан-туры җиткерә. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) шундый хәдисе бар: «Бер кешенең ризыгы – ике, ике кешенеке дүрт кешегә җитә». Ризык – Аллаһы Тәгалә биргән нигъмәт. Без аны тиешле урында, тиешле микъдарда гына кулланырга тиеш. Ризыкны тонналап исраф кыла торган илләр дә бар. Аллаһы Тәгалә исрафтан сакласын!

Бер хәдискә тукталып үтәсем килә. Пәйгамбәребез (с.г.в.) болай дип әйткән: «Кеше үзенең тулы карыныннан тагын да начаррак савытны беркайчан да тутырмаган. Адәм баласына үз көчендә булу өчен берничә кисәк ризык җитә. Күбрәк ашарга туры килсә, ашказанын өчкә бүлсен: бер өлеше – аш өчен (ризык), икенчесе – эчемлеккә (су, чәй), өченчесен сулыш алу (һава) өчен калдырсын». Кайберәүләребез шулкадәр күп итеп ашый, хәтта ашап бетергәч, ух-ух килеп утырабыз, аннары соң бернинди эш тә кыла алмыйча йөрибез.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) тагын шуны әйткән: «Берәрегезнең ризыгы төшеп китсә, аны күтәреп пычрактан чистартсын да ашасын, шайтанга калдырмасын. Бармакларындагы ризыкны ялап алмыйча, кульяулык белән сөртмәсен. Хакыйкатьтә сез бәрәкәтнең ризыкның кайсы өлешендә булуын белмисез».

:: Күпләр бары тик ризыкны гына исраф итәргә ярамый дип уйлый. Ләкин исраф башка нәрсәләрдә дә кагыла. Әйтик, вакытны бушка сарыф итү. Анысы турында ни диярсез?

– Исраф ризыкта гына түгел, һәрбер гамәлдә дә бар, һәрнәрсәдә чагыла. Тагын бер хәдискә мөрәҗәгать итик. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Биш әйбер килгәнче булган биш нәрсәнең кадерен белегез. Яшьлегеңне – картлык килгәнче. Сәламәтлегеңне – чир килгәнче. Байлыгыңны – ярлылык килгәнче. Буш вакытыңны – мәшгульлек, мәшәкатьләр килгәнче. Яшәвеңне – үлем килгәнче».

Вакытны без юк-барга сарыф итәргә тиеш түгел. Гамәл, гыйбадәт өчен вакыт бүлеп бирергә тиеш без. Пәйгамбәребез (с.г.в.) үзенең көнен өч өлешкә бүлә торган булган: гыйбадәткә, зекергә – бер өлеше, икенче өлеше – гаиләсе өчен, өченчесе – халык өчен, халык арасында вәгазь сөйләү, аларны дингә өндәү өчен. Ягъни адәм баласы да үз вакытын шулай бүлсә хәерле. Бер өлешен – гыйбадәткә, икенчесен – гаиләсенә, өченчесен – хезмәткә, тормышны алып баруга.

Күпләр, кызганыч, көнен кем беләндер буш сүз сөйләшеп, интернетта утырып, телевизор карап үткәрә. Аллаһы Тәгалә: «Хакыйкатьтә, һәр адәм баласы – хәсрәттә. Иман китереп, һәрвакыт изге гамәлләр кылган, бер-берсенә хактан һич тә аерылмаска өндәгән һәм бер-берсенә тормыш вә дин мәшәкатьләренә, килгән төрле авырлыкларга, бәла-казаларга сабыр итәргә, чыдамлы булырга өндәгән хак мөэминнәрдән кала», – ди.

:: Кайберәүләр исрафлыкны юмартлык белән дә бутарга мөмкин әле...

– Аллаһы Тәгалә: «Аллаһының коллары арасында шундыйлар бар: алар, малларын сарыф иткән вакытта, исраф кылучылар белән сараннар арасында урта бер юлны эзләрләр», – дип мөрәҗәгать итә безгә. Шуңа күрә дә без, бәндәләр, һәрвакыт урталык эзләргә тиеш.

:: Мал-мөлкәтне исраф кылу турында дин нинди фикердә?

– «Әл Нәхәл» сүрәсендә: «Аллаһ кайберәүләргә ризыкны күбрәк бирде», – диелә. Ягъни бүлешер өчен күбрәк бирелгән. Ятимнәргә, мохтаҗларга өлеш чыгарырга, мәсәлән.

Күпләребез мал-мөлкәтне исраф итү юнәлешендә алдынгылар сафында инде. Әйтик, кеше бер үк төрле әйбернең кыйммәтрәген сатып ала икән, бу да исрафка китерергә мөмкин. «Минем акчам күп», – дип, кыйммәтрәген алып, үзебезнең дәрәҗәле, тәкәббер икәнлегебезне күрсәтәбез.

Бервакыт пәйгамбәребездән (с.г.в.): «Тәһарәт алганда да су исраф саналамы әллә?» – дип сорыйлар. Ул: «Елга буенда булсаң да, суны кирәгеннән артык файдалану исраф була», – ди.

Гыйбрәт ал!

«Шайтан коткысында калдырмам»

Пәйгамбәребез (с.г.в.) белән Әбү Бәкер (р.г.) сөйләшеп утыралар икән, бер кяфер килеп, Әбү Бәкерне (р.г.) төрле сүзләр әйтеп мыскыллый башлый. Күпмедер вакыттан соң Әбү Бәкер (р.г.) җавап кайтара башлауга, пәйгамбәребез (с.г.в.) аны туктата: «Дәшмә», – ди.

Әбү Бәкер (р.г.), гаҗәпләнеп: «Ул миңа никадәр сүз әйтте, аны туктатмадың, мине беренче сүздән үк туктатасың», – ди икән.

Рәсүлебез (с.г.в.): «Ул сине сүккәндә, аның артында шайтан иде, синең артта фәрештә торды, син җавап кайтара башлауга, шайтан синең артыңа күчте, сине шайтан коткысында калдырасым килмәде», – дигән.

ru.freepik.com

Йөгез, бер дога!

ҮЛЕМ МИЗГЕЛЕНДӘ УКЫЛА

Пәйгамбәребез галәйһи вә сәлләм мәңгелеккә китәр алдыннан үлем түшәгендә ятканда болай дигән: «Аллаһуммә әгыйнний гамәраатил-мәүти вә сәкәраатилмәүүт».

Мәгънәсе: «Аллаһым! Үлемнең авырлыгыннан һәм үлгәндә үз-үземне белештермәүгә каршы миңа ярдәм ит».

Аннан соң пәйгамбәр галәйһи вә сәлләм үлгәнче бу доганы укыды:

«Аллаһуммә-гъфир лии вәрхәмнии вә әлхикъныи биррафиикыйл-әгъләә». Мәгънәсе: «Аллаһым! Мине гафу ит, миңа мәрхәмәтең белән кара һәм мине иң якын дуска (Сиңа) алып бар».

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Бер сүз җитә

Уйламый әйтелгәне дә, әйтелми калганы да куркыныч. Сүзнең көче дә, тәэсире дә зур – моны һәркем белә, әмма кайчак тиешенчә бәяләми. Сәхифәбездәге яңа сорау – җавап та тормыштагы әһәмиятле сүзләргә багышлана. Бүген без Татарстанның халык артисты Вадим ЗАХАРОВ белән сөйләштек.

:: Иң кадерле сүз?
– Әни.

:: Егылганда тартып торгызган сүз?
– Гаилә.

:: Бик каты яралаган, рәнҗеткән сүз?
– Сүз түгел, мөнәсәбәт яралый. Ә яралар төзәлә. Рәнҗегән юк.

:: Әйтәсе килеп тә, әйтә алмый калган сүз?
– Әнигә «Яратам!» дип аз әйтелде.

:: Бүген, хәзер ишетәсе килгән сүз?
– Җайланачак.

Вакыт бар чакта...

Кызыклы китаплар укып, матур-матур фильмнар карап калырга кирәк! Ә нәрсә карарга һәм нәрсә укырга белми аптыраган чакта, алып баручы Айваз Садыйров белән бергә төзегән исемлеккә күз салыгыз.

Фильм / сериал / мультфильмнар:

1. **«Чародей»** сериалы, 12+ (1995, реж. – Ноэль Прайс). *«Мин бала чакта телевизордан күрсәтелгән балалар сериалы. Сюжет буенча Пол исемле егет параллель дөньяга эләгә. Сериалны әле дә караштыргалыйм. Балаларыгыз белән карарга була».*
2. **«Мырау Батыр»** сериалы, 0+ (1989, реж. – Индус Үтәгәнов). *«Шулай ук балаларыгыз белән карарга мин тәкъдим иткән татар музыкаль сериалы. Интернетта да табарга була».*
3. **«Верные друзья»** фильмы, 0+ (1954, реж. – Михаил Калатозов). *«Рәхәт совет кинофильмы».*
4. **«Дорогая, я уменьшил детей»** фильмы, 6+ (1989, реж. – Джо Джонстон).
5. **«Душа»** мультфильмы, 6+ (2020, реж. – Пит Доктер, Кемп Пауэрс).

Китаплар / әсәрләр:

1. Джек Лондон **«Мартин Иден»**.
2. Чарльз Диккенс **«Приключения Оливера Твиста»**.
3. Фатих Хөсни **«Йөзек кашы»**.
4. Фатих Әмирхан **«Габделбасыйр гыйшкы»**. *«tatkniga.ru сайтында аудиоверсиясе бар. Кышкы урамга җәяүләп йөрергә чыксагыз, аны тыңлап барырга була. Мин шулай эшләргә яратам».*
5. О. Генри **«Дары волхвов»**.

ЕРАК ТӨШМӘГӘННӘР

Әтиеңнең яки әниеңнең бик популяр булуын аңлау ничегрәк икән ул? Танылган фамилия ничек һәм кайчан ярдәм итә? Бу сорауларны без, мәкальдәгечә, «агачыннан ерак төшмәгән алма»ларга – популяр артистларның танылган һәм танылып килүче балаларына бирдек.

«Әти, алар сине каян белә?»

Татарстанның халык артисты Әсхәт Хисмәтнең улы, баянчы **Булат ХИСМӘТОВ** кечкенә чакта әтисен танып эндәшүләренә аптырый торган булган. «Балалар бакчасына йөргәндә, бүтән балаларның әти-әниләре аның белән исәнләшә иде. Мин бит аларны белмим, шуңа әтидән: «Әти, алар сине каян белә?» – дип сорый идем. Шулай итеп, әтиемнең танылган кеше икәнен кечкенә вакытта ук аңладым. Аңа, танылган артист буларак, гел хөрмәт күрсәтәләр», – диде ул. Хисмәтов фамилиясен йөртүнең ярдәме дә тигән аңа. «Кайвакыт: «Син бит – Әсхәт Хисмәт малае», – дип танып алалар, ярдәм кирәк булса, булышалар. Фамилиям аркасында гына үземә карата ниндидер башка төрле мөнәсәбәт сизмим. Башкаларның миннән нәрсә көткәнен дә белмим», – дип сөйләде Булат. Ә халык артистының йөзенә кызыллык китерүне икеләтә гөнаһка тиңли ул.

«Фамилиямне файдаланганым юк»

Татарстанның халык артисты Рөстәм Закиров һәм Люция Мусинаның кызлары **Миләүшә ЗАКИРОВА** да бүген әти-әнисе юлыннан атлый. «Гаиләбез белән бергә төрле район-шәһәрләрдә концерт куеп йөри башлагач, әти-әниемне хөрмәт итеп, яратып, зал тутырып килүче тамашачыны күрдем. Аларның танылган, хөрмәтле җырчылар булуын шунда аңладым», – ди ул. Яшерми: бүген ул үзенә карата игътибарны да тоя, җаваплылыкның зур булуын да аңлый. «Ләкин минем беркайчан да фамилиямне файдаланганым юк. Чөнки әти безне һәрвакыт үз көчебезгә таянып, барына да үз тырышлыгыбыз белән ирешергә өйрәтте», – ди Миләүшә. Җырлаганда да аңа карата таләп зуррак. «Монысын да аңлыйм. Җырлаганда гына түгел, гомумән, үземне матур тотарга, әти-әнием биргән тәрбиягә, алар йөзенә тап төшермәскә тырышам. Шулай тиеш булганга түгел, үзем шулай теләгәнгә».

«Аңа кадәр ерак әле...»

Өйдә аның артист икәнен тоймадык. Танылган җырчы Дәниф Шәрәфетдиновның улы **Динар ШӘРӘФЕТДИНОВ** шулай ди. «Мин кечкенәдән гастрольләрдә йөрдем, әтине телевизор аша еш күрә идем. Кайбер сыйныфташларымның, укытучыларымның: «Дәниф Шәрәфетдиновның улы булу ничек ул?» – дип сораганнары хәтердә. Мин аларга ни дип җавап бирергә белми аптырый идем, чөнки өйдә ул гап-гади әти булды», – дип сөйләде ул безгә. Бүген Динар академик сәхнәләрдә дә еш чыгыш ясый. «Опера спектакльләрендә һәм концертларында сәхнәгә мине «Дәниф Шәрәфетдиновның улы Динар» дип түгел, ә «Динар Шәрәфетдинов» дип кенә чакыралар. Сөенәм. Әйе, мине сәхнәгә әтием алып чыкты, моның өчен мин аңа мең рәхмәтле. Ләкин мин үзем ирешкән уңышларымны фәкать фамилиямә бәйләп карауларын теләмим», – ди егет. Бүген ул әтисе күтәргән дәрәҗәне төшермәскә тырыша. «Аның осталыгына кадәр ерак әле миңа. Ләкин мин үз өстемдә эшлим, чөнки әтинең дә исеменә тап төшермәскә кирәк».

«Икеләтә җаваплылык тоям»

Ике яшендә үк әнисе Ләйсән Гыймаева белән «Татар җыры» сәхнәсенә чыккан **ТАҢСЫЛУ** бүген үзе дә сәхнә ярларга әзерләнә. Ул да – кечкенәдән гастрольләр «тәм»ен тойган бала. «Әти-әнием гел кайдадыр чыгыш ясады, мине дә үзләре белән йөрттеләр. Алар кечкенәдән гади кеше түгел иде минем өчен», – ди ул үзе. Фамилиягә килгәндә, бу җырлы гаиләдә алар – өчәү. Чын фамилияләрен (ә алар – Җиһангәрәевләр) белүчеләр азрак булгач, Таңсылу әйтмешли, «файда»сы да булмаган. «Дусларым татар эстрадасын тыңламый, шуңа да алар арасында минем кем баласы булуымны белүче бик аз. Ә минә татар эстрадасын күзәтеп баручылар белә», – ди Таңсылу. Җаваплылык хисе турында сорагач, беренче чиратта, өйдәге җаваплылык турында сөйләде ул: «Мин – гаиләдә иң өлкән бала. Ул яктан вазыйфаларым да, җаваплылыгым да җитәрлек. Әти-әнием өчен терәк булырга тырышам».

10 гыйнвар | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 02.05 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «ТУЗГАН ТОРАКТАН КҮЧ-КӘНДӘ» 16+
11.00, 00.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ...» 16+
13.00, 00.25 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Азбука долголетия» 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я» 12+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.30 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 16+
17.30 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00 «Гаилә учагы» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Ватандашлар» 16+
23.00 «БРИЛЛИАНТЫ ДЛЯ ДЖУЛЬЕТТЫ» 12+
01.15 «Точка опоры» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Башваткыч» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара»
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 21.25, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
09.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
10.00 «Халкым минем» 12+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 04.20 «Сөйләшергә вакыт» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
18.20 «Кәмит Җәвит» 16+
20.00, 00.15 «Гаилә учагы» 16+
23.10 «Кәмит Җәвит» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ
05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ДОКТОР ПРЕОБРАЖЕНСКИЙ» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 «ЛЕГЕНДА О СУРАМСКОЙ КРЕПОСТИ» 12+
01.35 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 12+
23.30 «САМА ВИНОВАТА?» 18+
00.50 «СКАЖИ ПРАВДУ» 12+
03.10 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ
06.00 «Лига в лицах» 12+
06.30 «Что за спорт?» 12+
07.00, 10.00, 12.50, 16.20, 03.55 Новости
07.05, 15.10, 18.20, 21.15, 00.00 Все на Матч!
10.05, 12.30 Специальный репортаж 12+
10.25 «Роуди» 12+
12.55 Смешанные единоборства. АСА. Виталий Слипенко против Устармагомеда Гаджидаудова 16+
13.55 «Один за всех» 16+
16.25, 01.00 «Вид сверху» 12+
16.55 Профессиональный бокс. Евгений Тищенко против Леона Харта. Бой за титул чемпиона по версии WBA 16+
18.45 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Витязь» (Московская область) – СКА (Санкт-Петербург)
21.55 Футбол. Суперкубок Испании. 1/2 финала. «Реал» (Мадрид) – «Атлетико»
01.30 «География спорта» 12+
02.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Автодор» (Саратов) – «Локомотив-Кубань» (Краснодар) 6+
04.00 Бильярд. «BetBoom Суперлига». Финал 0+

НТВ
05.10 «СТАРЫЕ КАДРЫ» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «БАЛАБОЛ» 16+
16.45 «ДНК» 16+
20.00 «БИМ» 16+
23.20 «Смехополис» 16+
00.45 «ЛЕГЕНДА ФЕРРАРИ» 16+
04.35 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+

ДОМАШНИЙ
07.30, 04.45 «Давай разведёмся!» 16+
08.30, 03.05 «Тест на отцовство» 16+
10.45, 23.30 «Понять. Простить» 16+
12.00, 00.55 «Порча» 16+
13.10, 01.45 «Знахарка» 16+
13.45, 02.10 «Верну любимого» 16+
14.20, 02.40 «Голоса ушедших душ» 16+
14.55 «УРОКИ СЧАСТЬЯ» 16+
19.00 «ЕСЛИ СЕРДЦЕ ДРОГНЕТ» 16+
05.35 «6 кадров» 16+
05.50 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 18.50 «Специальный репортаж» 16+
11.10, 13.25, 23.15 «12 СТУЛЬЕВ» 12+
14.45, 17.15, 03.45 «ВЫСШИЙ ПИЛОТАЖ» 16+
15.00 Военные новости 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Секретные материалы» 16+
22.45 «Между тем» 12+
02.05 «КУРЬЕР» 12+
03.30 «Оружие Победы» 12+

11 гыйнвар | Пәнҗешәмбе

ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «ТУЗГАН ТОРАКТАН КҮЧ-КӘНДӘ» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ...» 16+
13.00, 04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
14.00 «Память сердца» 16+
14.15 «Классный час» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.30 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 16+
17.30, 03.55 «Точка опоры» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Соотечественники» 16+
23.00 «БРИЛЛИАНТЫ ДЛЯ ДЖУЛЬЕТТЫ» 12+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Азбука долголетия» 16+
00.40 «Кто мы татары?» 12+
01.05 «Җырлыйк әле!» 12+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 04.20 «Кәмит Җәвит» 16+
09.30 «Гаилә учагы» 16+
10.00, 20.00 «Ватандашлар» 16+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
18.20, 23.10 «Сөйләшергә вакыт» 16+
21.25, 03.30 «Сакладым сине күңелемдә» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ
05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ДОКТОР ПРЕОБРАЖЕНСКИЙ» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 «АШИК-КЕРИБ» 12+
01.35 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 12+
23.30 «САМА ВИНОВАТА?» 18+
00.50 «СКАЖИ ПРАВДУ» 12+
03.10 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ
06.00 «Лига в лицах» 12+
06.30 «Вид сверху» 12+
07.00, 09.30, 16.20, 03.55 Новости
07.05, 15.10, 18.20, 21.15, 00.00 Все на Матч!
09.35 Лыжные гонки. Альфа-Банк Кубок России. Женщины. 10 км
11.25 Биатлон. Альфа-Банк Чемпионат России. Суперспринт. Женщины
12.15 Биатлон. Альфа-Банк Чемпионат России. Суперспринт. Мужчины
13.25 Лыжные гонки. Альфа-Банк Кубок России. Мужчины. 15 км
16.25, 01.00 «Большой хоккей» 12+
16.55 Смешанные единоборства. UFC. Марлон Вера против Кори Сэндхагена 16+
18.45 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. ЦСКА – «Динамо» (Москва)
21.55 Футбол. Суперкубок Испании. 1/2 финала. «Барселона» – «Осасуна»
01.30 «Что за спорт?» 12+
02.00 Дартс. OLIMPBET Чемпионат профессиональной лиги 0+
04.00 Лёгкая атлетика. «Рождественские старты» 0+

НТВ
05.10 «СТАРЫЕ КАДРЫ» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «БАЛАБОЛ» 16+
16.45 «ДНК» 16+
20.00 «БИМ» 16+
23.20 «Смехополис» 16+
00.45 «ЛЕГЕНДА ФЕРРАРИ» 16+

ДОМАШНИЙ
07.10, 04.45 «Давай разведёмся!» 16+
08.10, 03.05 «Тест на отцовство» 16+
10.25, 23.30 «Понять. Простить» 16+
11.40, 00.45 «Порча» 16+
12.45, 01.45 «Знахарка» 16+
13.20, 02.10 «Верну любимого» 16+
13.55, 02.40 «Голоса ушедших душ» 16+
14.30 «ЕЩЁ ОДНА ПОПЫТКА ПОЛЮБИТЬ» 16+
19.00 «СЕРАЯ МЫШЬ» 16+
05.35 «6 кадров» 16+
06.15 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 18.50 «Специальный репортаж» 16+
11.10, 01.45 «К ЧЕРНОМУ МОРЮ» 12+
12.40, 13.25 «КУРЬЕР» 12+
14.45, 17.15 «ВЫСШИЙ ПИЛОТАЖ» 16+
15.00 Военные новости 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Код доступа» 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ЖДИТЕ СВЯЗНОГО» 12+
00.40 «ТАЕЖНЫЙ МОРЯК» 12+
03.00 «СВИНАРКА И ПАСТУХ» 12+
04.25 «Движение неприсоединения. Вызов старому миру» 16+

12 гыйнвар | Җомга

ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести Приволжского федерального округа»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.15 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00 «Манзара» 16+
07.00, 20.30 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «ТУЗГАН ТОРАКТАН КҮЧКӘНДӘ» 16+
11.00 «Нәсыйхәт» 16+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ...» 16+
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 16+
14.15 «Наши герои» 16+
14.45, 02.10 «Семь дней +» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.30 «ДУСЛЫК ИЛЕНДӘ» 16+
16.45 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Трактор» – «Ак барс» 6+
20.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Юлчы» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Сөйләшергә вакыт» 16+
00.00 «БРИЛЛИАНТЫ ДЛЯ ДЖУЛЬЕТТЫ» 16+
00.50 «ВСТРЕТИМСЯ У ФОНТАНА» 0+
02.35 «Фолиант в столетнем переплете» 16+
02.50 Концерт 6+
03.25 «Җырлыйк әле!» 12+
04.20 «Әдәби хәзинә» 16+
04.45 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 18.20, 23.10, 04.20 «Ком сәгате» 16+
09.30, 16.30, 00.15 «Нәсыйхәт» 16+
10.00, 20.30, 02.00 «Заман көзгесе» 6+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 01.05 «Сакладым сине күңелемдә» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
19.10, 22.15, 02.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Ватандашлар» 16+
21.25 «Кто мы татары?» 12+
21.55 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ
05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
18.40 «Человек и закон» 16+
19.45 «Поле чудес» 16+
21.00 «Время»
21.45 «Фантастика» 12+
00.00 «Матадор» 18+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
09.30 «Утро России»
14.55 «Судьба человека» 12+
16.30 «Прямой эфир» 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 12+
23.30 «ЭКИПАЖ» 6+
01.50 «ОХОТА НА ПИРАНЬЮ» 16+

МАТЧ ТВ
06.00 «Лига в лицах» 12+
06.30 «Большой хоккей» 12+
07.00, 10.00, 12.50, 16.20, 03.55 Новости
07.05, 15.10, 21.45, 00.30 Все на Матч!
10.05 «Небесная грация» 0+
10.25 «В ПОГОНЕ ЗА ВЕТРОМ» 12+
12.30 «Лица страны» 12+
12.55 Смешанные единоборства. АСА 16+
13.55 «Король ринга» 12+
16.25 Матч! Парад 6+
16.55 Мини-футбол. Чемпионат России. ПАРИ-Суперлига. «Тюмень» – «Торпедо» (Нижегородская область)
18.45 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Спартак» (Москва) – СКА (Санкт-Петербург)
22.25 Футбол. Чемпионат Германии. «Бавария» – «Хоффенхайм»
01.30 «Магия большого спорта. Лыжный спорт» 12+
02.00 Дартс. OLIMPBET Чемпионат профессиональной лиги 0+
04.00 Смешанные единоборства. One FC

НТВ
05.05 «СТАРЫЕ КАДРЫ» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «БАЛАБОЛ» 16+
16.45 «ДНК» 16+
20.00 «БИМ» 16+
23.05 «Смехополис» 16+
00.30 «Я – АНГИНА!» 16+
03.35 «ВО ВЕКИ ВЕЧНЫЕ» 16+

ДОМАШНИЙ
07.10, 04.40 «Давай разведёмся!» 16+
08.10, 03.00 «Тест на отцовство» 16+
10.25, 23.20 «Понять. Простить» 16+
11.40, 00.35 «Порча» 16+
12.45, 01.40 «Знахарка» 16+
13.20, 02.05 «Верну любимого» 16+
13.55, 02.35 «Голоса ушедших душ» 16+
14.30 «БОЛЬШЕ ЧЕМ ПРИКОСНОВЕНИЕ» 16+
19.00 «ЕЩЁ ОДНА ЖИЗНЬ» 16+
05.30 «Знать будущее. Жизнь после Ванги» 16+
06.20 «КОМНАТА РОЗ» 16+

ЗВЕЗДА
05.20, 14.45, 17.15, 04.55 «ВЫСШИЙ ПИЛОТАЖ» 16+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.30 «ПРОПАВШАЯ ЭКСПЕДИЦИЯ» 12+
12.10, 13.25 «ЗОЛОТАЯ РЕЧКА» 12+
15.00 Военные новости 16+
18.45 «По горячим следам» 16+
19.40 «Загадки века» 12+
20.30 «Скрытые угрозы» 16+
21.20 «Специальный репортаж» 16+
22.00 «Здравствуйте, товарищи!» 16+
23.30 «Музыка+» 12+
00.50 «БЕЗЫМЯННАЯ ЗВЕЗДА» 12+
03.05 «ТАЕЖНЫЙ МОРЯК» 12+
04.10 «Зафронтовые разведчики» 16+

13 гыйнвар | Шимбә

ВГТРК ТАТАРСТАН

08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
07.00 «Sиңа Миннән Sәлам» 16+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00 «Туган авылым» 12+
11.30, 02.40 «Музыкальный майдан» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
13.30 «Гаилә учагы» 16+
14.00 Әлфия Авзалованың 90 еллыгына багышланган концерт 16+
16.30 «Күңелләрдә тальян моңнары» 6+
17.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
18.00, 04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
19.30, 21.30 Новости в субботу 16+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Жырлыйк әле!» 12+
22.00 «Кайт әйдә, Кыш бабай!» 6+
23.25 «Яңа ел бәлән!» 16+
03.05 «Әдәби хәзинә» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Сакладым сине күңелемдә» 16+
07.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам» 16+
09.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00, 18.15, 03.00 «Башваткыч» 12+
12.05, 19.05, 03.50 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Җырларым-моңнарым тик сезнең өчен» 16+
17.15 «Калеб» 16+
17.45, 05.05 «Халкым минем» 12+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Кайт әйдә, Кыш бабай!» 6+
21.45 «Яңа Гасыр»да Яңа ел!» 6+
01.00 И. Мәхмүтова. «Күрәсем килгән иде». К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле 16+
04.40 «Заман көзгесе» 6+
05.30 «Нәсыйхәт» 16+

1 КАНАЛ

06.00 «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00, 12.00 Новости
10.15 «Наше всё» 0+
11.05 «ПроУют» 0+
12.15 «Поехали!» 12+
13.15 «СТАРУШКИ В СНЕГАХ» 12+
14.55 «ОПЕРАЦИЯ «С НОВЫМ ГОДОМ!» 16+
17.05 «Угадай мелодию» 12+
18.00 Вечерние новости
18.20 «Сегодня вечером» 16+
19.55 «Кто хочет стать миллионером?» 12+
21.00 «Время»
21.35 Новогодняя ночь на Первом. 10 лет спустя 16+
01.55 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Вести. Местное время
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 17.00, 20.00 Вести
11.45 «Доктор Мясников» 12+
12.50 «БОЛЬШИЕ НАДЕЖДЫ» 12+
17.50 «Привет, Андрей!» 12+
21.20 «Аншлаг. Старый Новый год» 16+
00.00 Новогодний голубой огонёк – 2024
03.10 «УПРАВДОМША» 12+

МАТЧ ТВ

07.30, 16.25, 19.15 Новости
07.35, 16.30, 19.20, 22.30, 00.45 Все на Матч!
08.30 «Команда МАТЧ» 0+
08.35 Биатлон. Альфа-Банк Чемпионат России. Командная гонка. Женщины
10.10, 12.55 Лыжные гонки. Альфа-Банк Кубок России. Спринт
11.40 Биатлон. Альфа-Банк Чемпионат России. Командная гонка. Мужчины
14.50 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Локомотив-Кубань» (Краснодар) – ЦСКА
17.25 Мини-футбол. Чемпионат России. ПАРИ-Суперлига. «Кристалл» (Санкт-Петербург) – «Газпром-Югра» (Югорск)
20.25 Футбол. Чемпионат Германии. «Дармштадт» – «Боруссия» (Дортмунд)
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Монца» – «Интер»
01.30 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Женщины. «Локомотив» (Калининградская область) – «Атом-Курск» 6+
03.00 Смешанные единоборства. UFC. Магомед Анкалаев против Джонни Уокера

НТВ

05.00 «СТАРЫЕ КАДРЫ» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.20 «ТОНКАЯ ШТУЧКА» 16+
10.20 «Главная дорога» 16+
11.00 «Живая еда» 12+
12.00 «Основано на реальных событиях» 16+
15.20 «Игры разумов» 0+
16.20 «Следствие вели...» 16+
19.25 «Секрет на миллион» 16+
21.30 «Дискотека Суперстар!» 16+
01.20 «ПЕРВЫЙ ПАРЕНЬ НА ДЕРЕВНЕ» 12+
05.00 «Новогодняя сказка для взрослых» 16+

ДОМАШНИЙ

10.15, 02.30 «ИСПРАВЛЕННОМУ ВЕРИТЬ» 16+
14.45 «ИСПРАВЛЕННОМУ ВЕРИТЬ. ПАУТИНА» 16+
19.00 «ВОРОН» 16+
22.40 «СЛУЧАЙНЫЕ ВСТРЕЧИ» 16+
05.50 «6 кадров» 16+
06.05 «КОМНАТА РОЗ» 16+

ЗВЕЗДА

08.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
08.15 «Морской бой» 6+
09.20 «Освобождение» 16+
09.55 «МАТРОС ЧИЖИК» 6+
11.40 «Мужики» 16+
12.10 «СССР. Знак качества» 12+
13.15 «Не факт!» 12+
13.45 «Война миров» 16+
14.30 «Легенды науки» 12+
15.20 «Главный день» 16+
16.10 «Время героев» 16+
16.30, 19.25 «ЮНОСТЬ ПЕТРА» 12+
19.50 «В НАЧАЛЕ СЛАВНЫХ ДЕЛ» 12+
22.45 «ПРОПАВШАЯ ЭКСПЕДИЦИЯ» 12+
01.15 «ЗОЛОТАЯ РЕЧКА» 12+
02.50 «СВЕТЛЫЙ ПУТЬ» 12+
04.25 «ОПАСНЫЕ ТРОПЫ» 12+
05.30 «Хроника Победы» 16+

14 гыйнвар | Якшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

08.00 Местное время. Воскресенье

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Фәрештә түгел» 16+
08.00 «Адымнар» 16+
08.30 Мультфильмы 6+
08.45 «Әти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы-шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 0+
10.15 «Кызган казан» 16+
11.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 16+
13.00 «Видеоспорт» 16+
13.30 «Очрашулар эзләп» 16+
14.450 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
15.45 «Ком сәгате» 16+
16.45 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Нефтехимик» – «Ак барс» 6+
19.30, 22.30 «Семь дней» 16+
20.30 «Заман көзгесе» 6+
21.00 «Болгар радиосы» концерты 16+
21.30 «Әй, язмыш, язмыш...» 16 +
23.30 «ПАГАНИНИ. СКРИПАЧ ДЬЯВОЛА» 12+
02.00 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Башваткыч» 12+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+
05.50 Татарстан хәбәрләре 16+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять»
07.00 «Адымнар» 16+
07.30 «Кто мы татары?» 12+
08.00 «Гомер бер бөртек» 16+
09.00, 03.40 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
10.00 «Кызган казан» 16+
10.30 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00, 04.35 «Гаилә учагы» 16+
13.30 Татарстанның халык артисты Әлфия Авзалованың 90 еллыгына багышланган концерт 16+
15.45 «ҮКСЕЗЛӘР» 16+
17.15, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит» 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате» 16+
20.00 «Семь дней» 16+
21.50 «Мин бу җирне матурларга тудым» 6+
01.05 «Манзара» 16+
02.45 «Шаян хәллар» 16+
03.15 «Әдәби хәзинә» 6+
05.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

06.00, 10.00, 12.00 Новости
06.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион» 12+
09.40 «Непутевые заметки» 12+
10.15 «Играем свадьбу!» 12+
11.05 «Жизнь других» 12+
12.15 «Повара на колесах» 12+
13.10 «Видели видео?» 0+
14.40 «Алексей Булдаков. «Ну вы, блин, даете!» 12+
15.35 «ОСОБЕННОСТИ НАЦИОНАЛЬНОЙ ОХОТЫ В ЗИМНИЙ ПЕРИОД» 16+
17.05 «Угадай мелодию» 12+
18.00 Вечерние новости
19.00 «Лучше всех!» 0+
21.00 «Время»
23.00 «КОНТЕЙНЕР» 16+
00.50 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

06.20, 01.30 «СКАЗКИ РУБЛЁВСКОГО ЛЕСА» 12+
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома»
09.25 «Утренняя почта»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 17.00 Вести
11.45 «Большие перемены»
12.50 «БОЛЬШИЕ НАДЕЖДЫ» 12+
17.50 «Песни от всей души» 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Что за спорт?» 12+
06.30 Матч! Парад 2023 6+
07.00, 08.30, 13.45, 21.00 Новости
07.05, 13.50, 16.30, 21.05, 00.20 Все на Матч!
08.35 Биатлон. Альфа-Банк Чемпионат России. Масс-старт. Женщины
09.50 Лыжные гонки. Альфа-Банк Кубок России. Скиатлон. Женщины
11.00 Биатлон с Дмитрием Губерниевым
11.25 Биатлон. Альфа-Банк Чемпионат России. Масс-старт. Мужчины
12.25 Лыжные гонки. Альфа-Банк Кубок России. Скиатлон. Мужчины
14.55 Гандбол. Чемпионат России. OLIMPBET Суперлига. Женщины. ЦСКА – «Ростов-Дон» (Ростов-на-Дону)
17.00 Бадминтон. Всероссийские соревнования «Новогодний волан»
19.30 Смешанные единоборства. UFC. Магомед Анкалаев против Джонни Уокера 16+
21.50 Футбол. Суперкубок Испании.
01.10 Автоспорт. Рождественская гонка чемпионов 6+

НТВ

05.50 «СТАРЫЕ КАДРЫ» 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача» 16+
11.00 «Чудо техники» 12+
11.50 «Дачный ответ» 0+
13.00 «НашПотребНадзор» 16+
14.00 «Однажды...» 16+
15.20 «Игры разумов» (0+)
16.20 «Следствие вели...» 16+
19.35 «Квартирник НТВ у Маргулиса. Новоселье по-новогоднему» 16+
22.45 «Новогодняя Маска» 12+

ДОМАШНИЙ

10.00 «ЖЕРТВА ЛЮБВИ» 16+
19.00 «ВОРОН» 16+
22.40 «КРЕСТЕЦКАЯ ВЫШИВКА» 16+
02.30 «ИСПРАВЛЕННОМУ ВЕРИТЬ. ПАУТИНА» 16+
05.35 «6 кадров» 16+
05.40 «Знать будущее. Жизнь после Ванги» 16+

ЗВЕЗДА

06.05 «ЖДИТЕ СВЯЗНОГО» 12+
07.25 «В НЕБЕ «НОЧНЫЕ ВЕДЬМЫ» 12+
09.00 «Новости недели» 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.40 «Скрытые угрозы» 16+
11.30 «Код доступа» 12+
12.20 «Легенды армии» 12+
13.15 «Специальный репортаж» 16+
13.55, 03.25 «Забытые войны России» 16+
18.00 Главное 16+
19.45 «Легенды советского сыска» 16+
23.00 «Фетисов» 12+
23.50 «ГДЕ 042?» 12+
01.10 «МАТРОС ЧИЖИК» 6+
02.35 «Царь-башня: легенды Останкино» 12+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?

Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 8 гыйнвар

06.00 «Яңа көн»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.00 Вести радио России
07.10 Туры элемтә
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10 Туфан Миңнуллин. «Акбай, Тәмлетамак һәм этбүреләр». Г. Камал ис. ТДАТ спектакле
13.10 «Татарстан дулкынында»
18.10 Яңалыклар
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

Сишәмбе, 9 гыйнвар

06.00 «Новый день»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.45 «Актуальное интервью»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.10 Прямой эфир
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар
11.20 «Пар канатлар»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Композитор Нәҗип Җиһанов әсәрләре

Чәршәмбе, 10 гыйнвар

06.00 «Яңа көн»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.45 «Юллар чатында»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.00 Вести радио России
07.20 Туры элемтә
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар
11.20 «Актуальное интервью»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Время молодых»
18.25 Рафис Корбан шигырьләренә җырлар

Пәнҗешәмбе, 11 гыйнвар

06.00 «Новый день»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.45 «Перекресток»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.00 Вести радио России
07.10 Прямой эфир
8.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «На волне Татарстана»
15.20 «Офыклар»
18.25 «Газиз тавышлар»

Җомга, 12 гыйнвар

06.00 «Иртәнге нур»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.00 Вести радио России
07.10 Туры элемтә
8.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар
11.20 Вести ПФО
11.30 «Доброе братство лучше богатства»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Лирик музыка концерты

Шимбә, 13 гыйнвар

08.10 «Чыршы әйләнәсендә». Әдәби-музыкаль композиция
09.00, 11.00, 12.00, 14.00, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Гөлбакча»
10.30 «7 көн»
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 «Мин әтине өйрәтәм». Радиосериал
11.25 Татар халык көйләре
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 Фатих Хәсни «Йөзек кашы». Радиоспектакль

Якшәмбе, 14 гыйнвар

08.10 «Между Волгой и Уралом»
09.00, 11.00, 12.00, 14.00, 16.00, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Кәмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней»
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Ял концерты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10, 16.10 «Фатих Хәсни «Йөзек кашы». Радиоспектакль

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

АННАН ҮРНӘК АЛЫГЫЗ!

Замана балалары шаккатыра. Кемдер 2–3 яшьтән укырга өйрәнгән, кемдер математиканы су урынына эчә. Арада Данияр Шакиров кебек ике айлык чагында ук йөзә башлаганнары да бар. Укуда һәм спортта, сәнгатьтә дә калышмый алар. Кайберләре эшмәкәрлектә дә сынатмый. Кыскасы, һәркайсының – үз таланты. «ВТ» битләрендә иң осталарны барларга булдык.

Данияр ШАКИРОВ, 4 яшь (Биектау районының «Бөреле» совхозы)

Данияр ике айлык чагыннан ук йөзәргә өйрәнгән. Хәзер Биектауда «Инеш» бассейнында спортчыларны әзерли торган махсус төркемдә шөгыльләнә. Ул инде су астындагы уенчыкларны бик тиз эзләп таба икән.

– Яхшы тренер таптык та ышанып тапшырдык. Баланы җәллләү хисе тумады. Әтисе дә спортчы аның, – ди әнисе Фәйрүзә.

Бакчага да бик иртә – 1 яшен тутырыга ук китә ул. Юк, әнисе тизрәк эшкә чыгу өчен түгел. Фәйрүзәнең улының сәләтен тизрәк ачасы килә. 2 яшьтә инде ул әлифбадагы барлык хәрефләрне таный, ә өч яшь ярымнан иҗекләп укый башлый. Өч яшьтән инглиз телен өйрәнә. Математика белән дә дус: 100гә кадәр саный, куша һәм ала белә. Конструктор, лего, пазл җыю өчен аңа рәсемгә бер мәртәбә карау да җитә. Әле ул – шахматчы да! Монысына Наил бабасы өйрәткән. Ә менә рәсем ясарга яратмый. Футбол, хоккей түгәрәгенә дә биреп караганнар, анысына да исе китмәгән. Аның каравы биисе килә. Монысын әлегә кичектереп тормакчылар.

Шакировларга бакчада да, таныш-белешләре дә еш кына: «Сезнең балагыз – вундеркинд», – дип әйтәләр икән. Аларда баладан даһи ясау теләге бөтенләй юк. «Җиргә һәр бала үз сәләте, миссиясе белән туа. Без, әти-әниләр, шул сәләтне ачарга, балага үз юлын табарга булышырга тиеш», – ди алар.

Зөбәйдә ФӘЛӘХИЕВА, 16 яшь (Теләче)

Зөбәйдә – Иске Җөри авылы кызы. Теләче мәктәбендә 10 нчы сыйныфта укый. Төрекчә иркен аралаша. Хәзер инглиз телен онлайн өйрәнә. Татар теле һәм әдәбияты республика бәйгесендә өч ел рәттән җиңгән һәм халыкара олимпиадада призер булган. Узган ел бөтенроссия шәҗәрә бәйгесендә Гран-при откан. Фәләхиевләр, гаиләләре белән «Тарихта без эзлебез» бәйгесендә катнашып, зона ярышында икенче урын алган.

Зөбәйдә 12 буын әби-бабасын эзләп тапкан. Бу эшкә ике ел элек тотынган. Әтисе Мөхәммәт – физкультура укытучысы. Аңа да: «Әйдә, моны эзлик, әйдә тегене», – дип, идея биреп кенә тора икән.

Кул көрәше буенча да районда беренче урыннар ала Зөбәйдә. Камыр ризыклары пешерә, сәйләннән төрле әйберләр ясый. Энеләренә, үзенә киемнәр дә тегә.

Динар МИҢНЕКӘЕВ, 8 яшь (Казандагы «Адымнар» мәктәбе укучысы)

Динар 2 нче сыйныфта укый. Ул – «Татар малае» бәйгесенең район этабы җиңүчесе. «Шаян ТВ» каналында күп тапкыр чыгыш ясаганы, «Без – Тукай оныклары» тапшыруында катнашканы бар. Яраткан шөгыле – китап уку. Музыка мәктәбенә барырга да өлгерә ул. Әле КФУдагы медиа мәктәпкә укырга да алганнар үзен.

Миңнекәевләр гаиләдә бары татарча гына аралаша. Шуңа күрә ул-кызлары кечкенәдән татар җанлы булып үсә. Динар беренче рус сүзләрен бакчага баргач ишеткән. Укырга 5 яшьлек чагында шунда өйрәнгән.

– Ике яшьтә улыбыз «зинһар өчен», «әлбәттә» дип сөйләшә иде инде. Башта телевизор караткадык. Беренче караган каналы – «Шаян ТВ», – ди әнисе Динара.

Гадәттә бала-чага, кибеткә кергәч, уенчыкка йөгерсә, Динар китап янында мәш килә. Әнисен дә: «Әйдә, китап кибетенә», «Әйдә, «әдәби кафе»га барыйк», – дип аптырата икән. 100ләп китап укыган инде. Моннан тыш, «Сабантуй», «Салават күпере» журналларын да яздырталар. Тәнәфес вакытында да китап укый. Укытучысы кайчак: «Ял ит инде», – дип кисәтү дә ясый икән.

Руфинә ГАЗЫЙМОВА, 10 яшь (Әтнә районының Күлле-Киме авылы)

Руфинә 4 нче сыйныфта белем ала. Аның билбаулы көрәш буенча республика ярышларында җиңүләр яулаганы бар. Көрәш белән мәктәпкә укырга кергәч үк шөгыльләнә башлый. Әтнә районындагы бердәнбер көрәшче кыз ул. Көрәш серләренә аны тренер Радик Шәрәфиев өйрәтә. Абыйсы Рәнис белән бергәләп йөриләр. Әнисе Ләйсән Газыймова әйтүенчә, җиңелүне кызы бик авыр кичерә. Аңа гел беренче урын гына кирәк.

– Син бит – кыз бала, сәламәтлегеңә зыян килер, дип тә әйтеп карадык. Тик аның – үз фикере. Көрәшергә бик ярата. Кызыбыз бик җитез һәм шук. Аңа тренировкада малайлар белән бил алышырга туры килә. Авырлыгы 36 кило гына булса да, бирешми. Волейбол, чаңгы, йөгерү кебек спорт ярышларында да теләп катнаша. Укуда да калышмый: алган билгеләре «4ле» дә «5ле». Биергә, җырларга да оста, – ди Ләйсән Газыймова.

Гыймран АБДУЛЛИН, 16 яшь (Казан)

Гыймран Казандагы 2 нче лицей-интернатта 10 нчы сыйныфта укый. Ул быел информатика буенча халыкара олимпиадада алтын медаль яулады. Лицей-интернатка 6 нчы сыйныфка Уфадан килгән. Тора-бара гаиләсе дә Казанга күченгән.

Гыймран башта математиканы күбрәк яратса, хәзер күңеленә информатика якынрак. Кечкенәдән Рубик кубигын җыярга яраткан. Компьютерда гына утырмый, дуслар белән аралашырга, спорт белән шөгыльләнергә дә вакыт таба. Хоббие – баскетбол, футбол уйнау.

– Улыбыз тырышлыгы белән алдыра. Бу очракта 99 процент тырышлык дияр идем. Халыкара олимпиадага җәй буе әзерләнде. Көн тәртибе билгеле, шуннан тайпылмый. Бик «дөрес» бала ул безнең, – ди әнисе Ләйсән.

Илкүләм олимпиада җиңүчеләре имтихансыз гына илнең теләсә кайсы вузына укырга керә ала. Гыймран исә Мәскәү вузын сайларга җыена.

Алмаз ГАТИН, 10 яшь (Арча)

Алмаз Арчаның 6 нчы мәктәбендә 4 нче сыйныфта укый. Узган ел ул шахмат буенча республика беренчелеген откан. Бу – аның иң зур уңышы.

Моңа кадәр алар Якутиянең Айхал шәһәрендә яшәгән. Алмаз 6 яшьлек чагында шахмат уйнарга өйрәнгән. Ковид башлану сәбәпле, түгәрәккә нибары өч ай гына йөргән ул. Ләкин шушы вакыт эчендә тренеры Владимир Каланчев малайда әлеге спорт төренә мәхәббәт уята алган. Өч ел элек Арчага күченеп кайтканнар. Алмаз анда Айдар Яхин җитәкләгән түгәрәккә йөри. Соңгы ике елда атнага өч мәртәбә Казандагы республика олимпия резервы спорт мәктәбендә шөгыльләнә. Остазы – Алмаз Куликов. Моннан тыш, өстәмә онлайн дәресләр ала.

Алмаз кечкенә чагында ук тиктормас булган. Шахматны утырып түгел, басып уйнаган. Дәрестә кайчак үзе дә сизмәстән шахмат дөньясына кереп китә икән. Әлеге гаилә, төпле белем биргән өчен, башлангыч сыйныф укытучысы Ләйсән Алмаевага рәхмәтле. Алмаз инде татарча яхшырак сөйләшә башлаган.

Сәрия МИФТАХОВА

vk.com

КАЙДА ДА БӘЙРӘМ

ЯҢА ЕЛНЫ НИЧЕК КАРШЫЛАДЫК?

Шушы көннәрдә Татарстанда яшәүче чит ил кешеләре белән дә аралашып алдык әле. Җир шарында яшәүчеләр өчен Яңа ел бәйрәме уртак кебек үзе, әмма үзенчәлекләре булмый калмас дигән фикердән чыгып, шул хакта сораштык. Арада, бәлки, күңел дәфтәренә теркәп куярлыклары да бардыр.

Корея

Рудольф КИМ,
Казанда яшәүче кореялыларның милли-мәдәни автономиясе җитәкчесе

Бездә Яңа ел Соллаль дип атала. Кореялылар тормышында төп бәйрәмнәрнең берсе. Ай календаре буенча исәпләнгән яңа елның беренче көне. Быел ул 10 февральгә туры килә. Элек Кореяда Яңа елны 14 көн бәйрәм итәләр иде. Тора-бара ялның артык күп булуын аңладылар да өч көнгә калдырдылар. Гореф-гадәт буенча бу көннәрдә бар кеше туган авылларына, әти-әниләре янына юл ала, шуңа күрә шәһәрләр бушап кала. Хәтта күп кенә кибетләр дә ябыла. Нигә дисәң, кибетчеләрнең дә туган йортларына кайтасы бар.

Бәйрәм көннәрендә гореф-гадәт буенча дөге салмасы пешерәләр. Ул ттоккук дип атала. Тагын панчан дигән салат әзерлиләр. Балалар белән һавага очыргыч җибәрәләр. Бәйрәмнең өченче көнендә һәркем түземсезлек белән ай калыкканын көтә. Әгәр ай ачык, үтә күренмәле булса, һава торышы әйбәт, уңыш мул булыр дип фаразлана. Айның ак төстәгесе – яңгырлар, кызыл төстәгесе корылык китерә дип фаразлана.

Казанда без Яңа елны, башкаларга ияреп, элегрәк рестораннарда, кафеларда үткәрә идек. Инде берничә ел үзешчән сәнгать коллективлары белән концерт оештырабыз. Тамашачылар күп килә, кайчагында хәтта Дуслык йортындагы залга сыймыйлар. Ике бию ансамблебез бар, яшьләр поп-музыка юнәлеше буенча үзләренекен оештырды. Бүләкләргә килгәндә, без тормышта кирәкле әйберләр бирергә яратабыз. Гадәттә ул азык-төлек, бизәнү әйберләре, акча булырга мөмкин. Шуңа мин кореялыларны әллә ни романтик хисләргә бирелүчән дип әйтмәс идем.

Таҗикстан

Мәҗит УБОЙДУЛЛОЕВ,
Казан илкүләм тикшеренү-технология университеты профессоры

Таҗикстанда Яңа елны узган гасырның 1935 елында беренче тапкыр үткәрәләр. Шул вакытта кибетләрдә чыршы уенчыклары пәйда була. Дүшәнбе шәһәрендә традиция буенча чыршыны ел саен декабрь башында ук бизиләр. Быел илебезнең бәйсезлек алганына 31 ел булу уңаеннан аны 31 метр биеклектә ясадылар. Таҗикстанда Яңа ел символлары Кыш бабай белән Кар кызының үз исемнәре бар: Бабои Барфи һәм Барфак. Гадәттә балалар бүләкне алар кулыннан алырга тырыша, шуңа күрә әти-әниләре алдан ук хәстәрен күрә.

Таҗикстанда үткәрелә торган Яңа елның күзгә күренерлек аерым бер үзенчәлекләре бар, дип әйтмәс идем. Советлар Союзы чорында бергә яшәгәч, бәйрәмнәр дә уртакка әверелгән. Ә менә бәйсезлек алгач, Таҗикстанда милли Яңа ел – Нәүрүз киң колач белән үткәрелә башлады. Шуңа да карамастан, 1 гыйнварда үткәрелүче Яңа елны онытмыйлар. Бу көнне һәр йортта әфлисун һәм мандарин исе, өстәлдә – оливье, «тун» астында балык, винегрет, койка, шампан шәрабе... Болардан тыш Таҗикстанда өстәлгә күп итеп кипкән җимешләр, татлы ризыклар куялар. Чөнки бу киләсе ел тәмле-татлы һәм уңышлы булсын өчен кирәк дигән ырым яши. Ә менә төп ризыкны, күбесенчә сәламәтлекләренә карап, таҗиклар төрлечә әзерлиләр. Кемгәдер тавык, кемгәдер бәрән ите ошый. Берәүләр шашлык, икенчеләр пылау пешерә. Бер генә уртаклык бар: әзерләгән ризыкта ит мулдан булырга тиеш.

Без гаиләбез белән 2007 елдан бирле Казанда яшибез. Шуңа күрә җирле традицияләрне дә, үзебезнекен дә сакларга тырышабыз. Быел да торт, төрле салатлар, шул исәптән оливье әзерләдек. Әлбәттә инде, өстәлебезнең төп «кунагы» пылау булды.

Грузия

Майя ХУХУНАШВИЛИ,
«Сиони» милли-мәдәни автономия җитәкчесе

Грузиядә Яңа ел бәйрәмен бик яраталар, 1 гыйнварда бәйрәм итәләр. Чыршыбыз грузин телендә чичилаки дип атала. Элек бу көнне мылтыктан ату традициясе бар иде. Хәзер инде фейерверк кына кулланалар. Шулай да бер гореф-гадәт бик нык сакланып калган. Курантлар 12не сукканнан соң, йорт бусагасын кем беренче булып атлап керә, шул «бәхетле аяк» дип санала. Әмма бу – бик зур җаваплылык. Гаиләне бәхет кенә түгел, нинди дер күңелсезлек тә көтеп торырга мөмкин бит. Шуңа да теләсә кем атлап керергә җөрьәт итми. Әмма берәр тапкыр кереп, гаиләгә бәхет ишелсә, ел саен чакырулары көт тә тор. Бу йола бигрәк тә авылларда киң таралган. Элек шигырьләр сөйләгәннәр, аяк астына солы, бодай ярмалары сипкәннәр. Хәзер исә нинди дә булса бүләк алып киләләр. Кунак үзе дә буш кул белән китми.

Грузиядә Яңа елга бүләкләр бирешмиләр. Хәтта чыршы астына балаларга да күчтәнәчләр куймыйлар. Европадан мондый гореф-гадәтләр безгә ни сәбәпледер килеп җитмәгән.

Әмма ничек кенә булмасын, Яңа ел бәйрәмен үткәрмичә калмыйбыз. Мин Татарстанда күптәннән яшим. Совет чорында студент идем. Аннан туган ягыма кайтып киттем. Туксанынчы елларда бирле яңадан Казанда яшим. Бу бәйрәмдә без гадәттә Грузиядә булган гореф-гадәтләрне сакларга, милли ризыкларны әзерләргә тырышабыз, чөнки Яңа ел – гаилә бәйрәме. Туган илебез дә, торган җиребез дә бик якын. Быел да туганнарыбыз, милләттәшләребез белән җыелышып утырдык. Грек чикләвеге белән балдан гозинаки ясадык. Әйтергә кирәк, без мондый татлы ризыкны бары тик Яңа елга гына әзерлибез.

Габон

Нзенге АРНО,
Казан дәүләт аграр университеты аспиранты

Бездә дә Яңа елны 1 гыйнвар көнне зурлап үткәрәләр. Гаилә бәйрәме. Әби-бабай, әти-әни, балалар, оныклар бергә җыела. Өстәл әзерләп, төрле вакыйгаларны искә алып, иске ел белән хушлашабыз, яңа елга теләкләр телибез. Ашау-эчү гадәттәгечә. Ит, балык, яшелчәдән төрле ашлар пешерәбез. Бүләкләрне күбрәк балаларга әзерлибез. Өлкәннәргә кием, сувенирлар, сәяхәткә юлламалар бүләк итәбез.

Мин Казанда бер елдан артык яшим инде. Яңа елны икенче тапкыр Татарстандагы дусларым белән үткәрдем. Безнең сыйларны да истә калдырсыннар дип, «Габон сителендә шпинат» әзерләдем. «Бик тәмле», – дип мактадылар.

Әфганстан

Асефи Мөхәммәт ШӘРИФ,
«Әфганстан бердәмлеге» иҗтимагый оешмасы җитәкчесе

Әфганстанда Яңа елны 21 мартта, көн белән төн тигезләшкән көнне каршы алалар. Азиядә яшәүче халыклар өчен ул – Нәүрүз бәйрәме. Әфганстанда Руз-е Дехкан, ягъни Крестьян көне дип атала. Бәйрәмнең беренче биш көне һәм унөченче көне календарьда ял көннәре булып исәпләнә. Бәйрәм традиция буенча төрле төстәге әләмне күтәрүдән башлана. Аның ничек җилфердәвенә карап, киләсе елның нинди буласын фаразлыйлар. Әләм 9 көн буена эленеп торырга тиеш.

«Фәрештә»ләр өй борынча йөреп, сәламәтлек, имин тормыш телиләр. Өлкәннәргә сый-хөрмәт куелмаган йортны урап узалар. Димәк, бу – хуҗаларны да бәхет ел буена урап уза дигән сүз. Мондый хәлгә калмас өчен, бәйрәмгә һәркем алдан ук әзерләнә. Яңа елдан аермалы буларак, Руз-е Дехканны төн уртасында түгел, ә көндез каршылыйлар. Беренче көнне буразна йоласы үткәрәләр: буйволларның мөгезләрен майлыйлар, лента белән бизиләр һәм тантаналы төстә кырга чыгаралар. Беренче буразнаны сызу авылның иң хөрмәтле кешесенә – аксакалга тапшырыла. Аның артыннан ир-атлар кузгала. Бу йолада хатын-кызлар катнашмый. Алар аерым җыела. Беренче буразнага орлык сибүгә, кыр эшләренә тотыналар.

Яңа ел өстәлендә «с» хәрефенә башланган җиде ризык булырга тиеш: сабен (шытым биргән орлык), сир (сарымсак), синҗид (кыргый зәйтүн), сиб (алма), серкә, сатар (тимьян). Өстәлдәге буялган йомырка, көмеч һәм чиста су мул уңыш символлары булып санала. Исерткеч эчемлекләр кулланылмый, бу бәйрәмдә җиде төрле кипкән җимештән ясалган компот эчәләр. Унөченче көндә исә халык, табигать кочагына чыгып, пикник оештыра. Ел буена татлы минутлар күп булсын дип, ширбәт кебек тәм-томнар ашыйлар.

Без инде күптән Татарстанда яшибез. Кем чанасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың, дигәндәй, әлбәттә инде, Яңа елны каршыламый калмыйбыз. Быел да үз гореф-гадәтләребезнең иң яхшыларын гына истә тотып, матур итеп бәйрәм иттек. Яңа ел котлы булсын!

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде

СЫНАУДАН СОҢ КИЛГӘН БӘХЕТ

Бар да үзеңнән тора! Балтач районының Арбаш авылында гомер итүче Ринат ВАФИН әнә шулай ди. Моннан 13 ел элек булган фаҗига аның тормышын икегә бүлә. Үз аякларында йөргән чак һәм бүгенге көн. Эссе көнне, бераз хәл керсен дип, суга сикергән 23 яшьлек егет хастаханә караватында уяна.

– Без гаиләдә өч бала үстек. Абыемның гына гомере озын булмады.16 яшендә авырып китте ул. Без аның белән кечкенәдән спортны яраттык. Көрәшеп тә йөрдек. Абыемның имгәнүләре дә булгандыр. Аягы бик каты сызлый башлагач, аны хастаханәгә салдылар. Табиблар сөяк яман шеше диагнозы куйды. Аягын кискәч, терелер кебек иде. Тик гомерен саклап кала алмадылар, – дип искә ала Ринат.

Егет белән күңелсезлек 2010 елның эссе җәендә килеп чыга. Ринат дуслары белән су коенырга чыгып китә. Үзенә ни булганын әле дә аңламый ул. Йөгереп килеп суга сикергәнен һәм бата башлавын гына хәтерли.

– Кул һәм аякларым эшләми башлады. Сөйләшә дә алмыйм. Иптәшләремне чакырасым килә, тик булдыра алмыйм. Әкренләп бата башладым. Су астына төшәм дә аннан тагын өскә күтәреләм. Менә шулчакта үләм дип уйладым. Ә үләсе килми икән ул. Тизрәк Аллаһы Тәгаләдән ярдәм итүен сорап, бар белгән догаларымны укый башладым, – ди ул. – Миңа ни булганын башта дусларым да аңламаган. Бата башлаганымны күреп, ярдәмгә ашыкканнар. Әле ярый алар булган. Яр буена өстерәп алып чыгып, табиб чакыртканнар.

Ринат хастаханәдә аңына килә. Табиблар артык өметләндерми, якыннарына егетне өйгә алып кайтырга киңәш итәләр. Бер көннән артык яши алмас, диләр. Әмма берсе аның гомере өчен көрәшергә була. 9 көн Арча хастаханәсендә ятканнан соң, Ринатны Казанга җибәрәләр. Тормышка яңадан кайту шунда башлана. Аңа яңабаштан яшәргә өйрәнергә туры килә. Егет бер елга якын хастаханәдә дәвалана.

– Беренче тапкыр инвалид арбасына утырып урамга чыгуыма ничек сөенгәнемне белсәгез! Барысына да риза идем. Яшисе килү теләгем көчле булды. Шатланудан күңелем дә тулды, – ди Ринат. – Шөкер, авыр чагымда гел ярдәм итеп торучыларым күп булды. Ул чакта кыен иде. Үземне сабыр булырга өйрәттем. Тормышны ничек бар шулай кабул итәргә өйрәндем. Сәламәтлегемне кайгыртырга кирәк, дип үземә сүз бирдем. Гел күнегүләр ясый башладым. Махсус шөгыльләнә торган җиһазлар алып куйдым. Мәскәү табиблары, аягыңа басачаксың, дип тә сөендереп тора. Кем белә? Бәлки басармын да әле...

Алдагысын берәү дә белми. Әле кайчан гына кая барып бәрелергә белмәгән Ринат инде гаилә корып, сабыйлар үстерә. Кенәбаш кызы Галия белән башта дуслашып йөриләр, аннан гаилә коралар. Сөйгәненең беренче никахтан туган сабыен да үз кызы итеп ярата.

– 2019 елда гөрләтеп туй ясадык. Мин өйләнгәч, эти белән әнигә мәшәкать кимеде. Төп йортта бергә гомер итәбез. Тормышыбыз түгәрәк, бер-беребезне аңлап яшибез. Галия миңа яшәр өчен көч бирә. Тормышым бөтенләй үзгәрде. Үземнең кирәклегемне белеп, яратучым барын тоеп яшим. 2023 ел безне бик бәхетле итте. Галиям миңа тупырдап торган Әмир белән Сәмир исемле игезәк уллар алып кайтты. Шулар белән мәш киләбез. Тормыш кечкенәләр тирәсендә бөтерелә, – ди Ринат. – Яхшы уйлар белән генә яшәсәң, тормышның матурлыгын аңлап була. Мин язмышка хәзер рәхмәт укыйм. Тормышны аңларга өйрәткәне өчен рәхмәт. Сынаулардан соң бәхетле көннәр киләсен онытмагыз!

Ринат Вафинның шәхси архивыннан

Ринат язмышына шөкер итеп яши.

ХӘЙРИЯЧЕ АЛЬБИНА ИСМАЕВА:

«ЯХШЫЛЫК КАНГА СЕҢГӘН»

Кешеләрне сөендереп яши белү һәркемгә бирелмәгән. Кемдер күрсен, мактасын өчен башкарыла торган эш түгел бу. Йөрәк кушып, күңел теләп кенә яхшы гамәлләр кылып була. Түбән Камада яшәүче күп кенә изге эшләре белән башкаларга үрнәк булган Альбина Исмаева кешеләрне сөендереп яши. Әле күптән түгел генә мөмкинлеге чикләнгән кешеләрне эстрада җырчылары белән бер сәхнәгә җыеп, зур чара уздырды.

– Башкаларны шатландыру, аларга яхшылык эшләү безнең гаиләдә һәркемнең канына сеңгән ул. Әбием белән бабам да, әтием белән әнием дә, ирем, аның әти-әнисе дә гел кешеләрне ничек тә шатландырырга тырыша. Без шуны күреп үстек. Сау-сәламәт булып яшәп торганда, ничек инде мохтаҗларга булышмыйсың ди! Күңелем белән бар дөньяны акка күмәр идем мин. Авыруларны да сөендерәсем килә, өлкәннәргә дә күңел җылысыннан өлеш чыгарырга тырышам, – ди Альбина Исмаева.

Альбинаның әти-әнисе дә яхшылык эшләргә атлыгып тора. Алар, Тобольскида гомер итүче туганнарын эзләп, үзләренә алып кайткан. Өлфәт абый үзе генә гомер кичергән. Туганнар белән аралашып торсалар да, берара элемтә өзелеп киткән. Өлфәт абый шалтыратуга җавап бирми башлаган.

– Башта полициягә хәбәр иттек. Алар аның бик авыр хәлдә яшәвен әйткәч, бөтенебез юлга кузгалдык. Башта аны танымадык та. Чәчләре, сакаллары үскән. Аяклары бик начар йөри. Безне көчкә таныды. Өлфәт абыйны үзебезгә алып кайттык. Аны ялгызын гына калдыру куркыныч иде, – ди Альбина.

Альбина Исмаеваның шәхси архивыннан

Фаяз бабай һәркемгә бик рәхмәтле.

Альбинаның тормышында тагын бер бабай бар бит әле. Түбән Камада яшәүче Фаяз абый ул. Аны шәһәрдә бик күпләр белә.

– Балаларым белән урамга чыккан идем. Шунда инвалид коляскасына утырган бер бабайны күреп алдым. Аның яныннан тыныч кына үтеп китә алмадым. Шундый сөйкемле иде ул, – дип искә ала Альбина. – Бабайның аягын 1 ел элек кисканнәр икән. Өченче каттан үзе үрмәләп төшә. Ә коляскасын алып төшәр өчен берәр кешене көтәргә туры килә.

Бабайны видеога төшереп, социаль челтәрләргә куйгач, аңа яңа коляска алырга, акча җыешырга тәкъдим итә башлыйлар. Альбинага Башкортстан блогеры Рөстәм Нәбиевтән хәбәр килә: «Фаяз бабайга яхшы коляскаы үзем алып бирәм». Озак көттерми, вәгъдәсен дә үти. Түбән Камага килеп, коляскаы үзе тапшыра.

– Фаяз бабай бүләгемә бик сөенде. Мин сөендерәсе кешеләрне күңел кушуы буенча сайлап алам. Үземә дә рәхәт булып кала. Булдыра алганда ярдәм итәсе килә, – ди Рөстәм.

Күптән түгел Фаяз бабай сәхнәгә чыкты. Инвалидлар көненә атап үткәрелгән чарада ул коляскага утырган килеш биеп шаккатыр.

– Җырчылар белән физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләрне бер сәхнәгә җыясым килгән иде. Уйладым да Түбән Камада зур концерт оештырырга булдым. Тамашачының аягүрә басып алкышлавын күреп еладым хәтта. Менә бу зур бәхет иде, – ди Альбина. – Бөтен гаиләбез белән бер уйда, бер теләктә булгач, бик рәхәт. Иремнең әти-әнисенең бакча күршеләрендә янгын чыккач, аларга да кулдан килгәнчә ярдәм оештырган идек. Кемгә генә булышсак та, рәхмәтле кешеләр очрый. Безне онытмыйлар, якын итәләр. Туганлашып беттек инде. Шул кеше рәхмәтләре безне саклап йөртәдер, дим. Башкача мөмкин дә түгел.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

КЫЗЫЛ БУЛМАГАН ШАМИЛ

Якында гына булган әдәбиятыбыз һәм шәхесләребез бар. Ләкин алар борынгы әдәбияттан да ераграк. Чөнки кызыл чаршау белән томаланган. Еракта калган шәхесләрнең берсе – Шамил Усманов. Кем ул, нинди шәхес? Аның фаҗигасе нәрсәдә?

Татарстан радиосы «ата»сы, «кызыл» әдип турында аның хакында роман язучы Марат КӘБИРОВ белән сөйләштек.

:: Марат абый, быел Шамил Усмановның тууына 125 ел тулуны билгеләп үттек. Без аны Татарстанда радио оештыручы дип беләбез. Ул – нинди шәхес? Ни өчен аның исеме бик яңгырамый, өйрәнелми?

– Тарихи каһарманнар турында сүз барганда, иң авыры – аларның нинди шәхес икәнен ачыклау һәм алар яшәгән заманны аңлау. Чөнки безгә тарихны үз чорыбызның сәяси һәм иҗтимагый вазгыятенә ярашлы итеп калыплап бирәләр дә, без тарихның үзенә түгел, әнә шул калыпка карап фикер йөртергә тотынабыз. Тарих шул икән, дип уйлыйбыз. Шамил Усмановны да дистәләрчә еллар буена фәкать кызылга манып күрсәтергә тырыштылар. Шамилне сурәтләгән эпитетларга гына игътибар итсәк тә җитәдер: «кызыл комиссар», «революциянең беренче көннәреннән үк партия сафына баскан коммунист», «Гражданнар сугышы каһарманы» һ.б. Моңа аның әсәрләре дә беркадәр этәргеч биргәндер инде. Аларда бит күбесенчә гади халык тормышы, сыйнфый көрәш вакыйгалары сурәтләнә. Репрессиядән акланганнан соң, кабат сафка кайтарырга теләп «матурлау» омтылышы да бардыр. Ничек кенә булмасын, коммунистик система кысасы аша карау Шамилнең шәхесен бик нык чикләп күрсәтә. Исеме бүген яңгырамауның бер сәбәбе шуңа да бәйле. Безнең чор өчен сыйнфый көрәш, коммунистик идеяләр белән уртак нәрсәләр актуаль түгел. Һәм икенче бик мөһим сәбәп – аның милли җанлылыгы, татарның дәүләтчелеге өчен көрәшүче булуы. Милләт мәнфәгатен кайгырткан мәсьәләләрне ул бит төрле яссылыкта, хәтта иң югары даирәләрдә күтәреп чыга, чыгышлар ясый. Аны әледән-әле төрле төбәкләргә җибәрүләре дә власть өчен тарткалашучыларның Шамилне сәяси, милли аренадан читләштерергә тырышулары кебек тоела. Бу җәһәттән дә Шамил исемен яңгырату бүгенге вазгыять өчен бик актуаль түгел. Югыйсә без аны Мирсәет Солтангалиев һәм башка милләтпәрвәр шәхесләребез белән берлектә карарга тиеш идек. Мин әле аның революциягә кереп китүе дә әнә шул милли азатлыкка омтылуның бер чагылышы булмадымы икән дип уйлыйм. Аның бит әтисе дә – татар дәүләтчелеге турында хыялланып яшәгән шәхес. Ләкин максатлары бер булса да, алар икесе ике юлны сайлый. Һәрхәлдә, Шамилнең хәлиткеч гамәлләрен аның милли җанлылыгы белән аңлатырга була. Тормышының төп мотивы – шул. Ихлас җанлы кеше, нәрсәгәдер алына икән, аны җиренә җиткерми туктамый.

> Үз фикерен ачыктан-ачык җиткерә һәм аның өчен көрәшә белә. Төрле чыганакларда аны ярсу итеп сурәтлиләр. Бу аның нинди дә булса эшкә дәртләнеп тотынуын, үз-үзен аямый хәрәкәт итүен һәм башкаларны да артыннан ияртү сәләтен үзенә алады. Ә холыксызлыгын түгел. Чөнки тормышының бик күп күренешләрен искә алсаң, аның сабырлыгына, тотанаклылыгына шаккатарлык. Гаделлек тойгысы көчле.

Тагын бер кызык нәрсә: язган әсәрләре, ясаган чыгышлары бик күп булса да, Шамил теоретик түгел, ул – гамәли фикер йөртә торган шәхес, хәрәкәт кешесе. «Нинди шәхес ул?» дигән сорауга бер-ике җөмлә белән генә җавап бирерлек түгел. Ул – күпкырлы бик катлаулы, урыны белән хәтта каршылыклы шәхес.

:: Гомумән, совет чоры җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелгәнме? Әдәбиятын «кызыл» дип чикләү гаделме?

– Юк. Хәтта бөтенләй өйрәнелмәгән дип әйтергә дә мөмкин. Чын тарихны каплап, кызыл чаршау элеп куйганнар да, шул чаршаудагы бизәкләрне генә беркадәр үзгәртеп торганнар шикелле. Гел бертөрле булмасын, хәрәкәт билгесе сизелсен өчен. Тоталитар дәүләттә шунсыз мөмкин дә түгелдер инде. Ул революция һәм аннан соңгы елларның ерткычлыкларын чокып чыгара башласаң, СССР шундук җимерелеп төшәр иде. Коточкыч дәвер бит ул. Менә бездә «Гражданнар сугышы» дигән төшенчә бар. Гомумән, Гражданнар сугышын без «аклар» белән «кызыллар» сугышы рәвешендәрәк күзаллап яшәдек. Алай гади түгел бит инде. «Аклар» дигәнебез үзләре үк әллә ничә төрле юнәлешне, төркемне эченә ала. Кайчагында алар үзара дошманлашып китә. «Кызыллар» дигәне дә шулай. Кемнең дус, кемнең дошман икәнен белерлек тә түгел. Һәм белмиләр дә. Монда бөтен кеше белән бөтен кеше сугыша. Туган белән туган сугыша. Бөтенесе дошман. Гражданнарның үзара сугышуы. Һәм ул сугышның кайчан башланып, кайчан бетүен дә тәгаен әйтерлек түгел. Утыз җиденче еллны да шул ук Гражданнар сугышының бер чагылышы итеп карап була бит инде. Монда да фронт юк, әмма шундый ук дошманлык бөҗрасы. Бары тик кораллар гына үзгә. Кылыч белән түгел, әсүз, яла белән кисәләр, доносляр яудыралар. Чынлабрак уйласаң, Гражданнар сугышы ул – Россия халыклары өчен Икенче Бөтендөнья сугышыннан да хәтәррәк фаҗига. Шамил Усмановның Гражданнар сугышы турындагы әсәрләре бик күп. Аларда вакыйгалар «кызыллар» ягыннан сурәтләнсә дә, объективлык бар. Кечкенә эпизодлар, күренешләр, саран гына сурәтләүләр, диалоглар аша бирә ул аны. Артык басым ясамыйча гына. Ләкин менә шул вак детальләр чор чынбарлыгын, дәвер атмосферасын тудыра.

vk.com

:: Шамил Усмановның кызы Айсылуның хатирәләре барлыгы мәгълүм. Синеңчә, ул – бәхетле кызмы? Әтисен ничек сурәтли?

– Аны иң төп һәм бай чыганакларның берсе дияргә кирәктер. Шамил начар әти булмагандыр инде. Туктаусыз вакыйгалар казанында кайнаса да, кызын онытмый ул. Зоопаркка да алып бара, циркка да. Төрле чараларга ияртеп йөртә. Айсылу да гел әтисе янында булырга тырыша. Ата белән кыз арасындагы якты мөнәсәбәт инде. Хәтта кулга алынганда да Айсылу озатып кала. Әтисе аңа: «Борчылма, кызым, тиздән кайтырмын», – дип китә. Кызы борчылмый, әтисенә ышана, кайтуын көтә... Көтеп ала алмый гына...

> Әтисе турында Айсылу бик яратып яза. Совет чорында булгач, бөтен хатирәләрен дә китапка кертә алмагандыр инде. Күзгә-күз карашып сөйләшкәндә әллә нәрсәләр ачыкланыр иде дә бит. Кызганыч ки, Шамилне белгән яки аның тормышын җитди өйрәнгән кешеләрнең берсе дә диярлек бүген исән түгел. «Шамил Усманов турында истәлекләр» кебегрәк китап та юк.

Бу аны бүгенгедән бераз ерагайта. Гомумән, татарның күренекле шәхесләре бик күп. Менә шулар турында хатирәләр тупланган китаплар чыгып барсын иде. Тарихи мәгълүматның иң чыны, иң тересе әнә шундый язмаларда сакланып кала бит ул. Бу җәһәттән Айсылу Усманова-Сагайдакның хезмәте бәяләп бетергесез. Әтисенә һәйкәл куеп киткән ул.

:: Галимҗан Ибраһимовның әсәрләрен еш кына татар әдәби теле үрнәге итеп күрсәтәләр. Ә Шамил Усманов әсәрләренең кыйммәте нәрсәдә? Аларны яңадан дөньяга чыгарырга кирәкме?

– Алдарак әйтә башлаган идем. Аның прозасы үзенә бертөрле. Гади, аңлаешлы, әкият укыган кебек тиз һәм җиңел укыла. Хәтта беркатлы кебек тә тоелып китә. Тик бу беренче карашка гына. Ә чынында автор хәтта катлаулы күренешләрне дә бернинди көчәнүсез, табигый итеп сурәтли. Менә без тирә-якка каранабыз бит инде, көндәлек нәрсәләрдән карашыбыз шуып уза, бернинди әһәмиятле әйбер дә юктыр сыман тоела. Ә асылда шуларның барысы да әһәмиятле: урам буйлап агылган халык та, машина юлындагы «бөке» дә, метро ишеге янында сабыен кочаклап утырган теләнче хатын да, ресторан төбенә килеп туктаган ялтыр җип та... Чөнки шул вак-төяк кебек күренешләр тормышны хасил итә һәм үзләре дә безнең яшәештән барлыкка килә. Шамил Усманов әсәрләре дә шулай. Тормыш агачыннан өзеп алып, китап арасына кыстырылган тере яфраклар шикелле. Кайбер хикәяләрендә чор, сыйнфый көрәш декорация кебек кенә кала. «Кызыллар» – «аклар», байлар – ярлылар кебек нәрсәләрне бернинди

сәясәткә бәйләнмәгән, әйтик, шахматтагы «аклар – каралар» төшенчәсе белән алыштырсаң да, әсәрләренең тәэсир көче югалмас иде. Һәм иң кызыгы: ул әллә ничәшәр битлек сурәтләүләр таләп ителгән күренешне дә бер-ике деталь аша күрсәтә белә. Безнең чорның хәбәр сөйләүгә корылган прозасы янында Шамил Усманов хикәяләре күрсәтә белү маһирлыгы белән сокландыра. Аның яхшы әсәрләре сүзләр ярдәмендә тудырылган кино кебек.

Дөньяга чыгарырга кирәк, әлбәттә. Рухи мирасыбыз бит ул. Бәлки, кайбер урыннарда аңлатмалар бирү дә зыян итми торгандыр. Гомумән, безнең әдәбиятны һәртөрле «изм»нардан арындырып, бәйсез караш белән өр-яңадан бәяләргә кирәк.

:: Радио оештыру нечкәлекләре турында да берничә сүз әйтик әле.

– Оештыруы бер әле аның. Шамил Усманов тумаган булса да, Татарстанга радио кермичә калмас иде. Тик Шамил аны 1922 елда ук кузгата. Бары тик биш елдан соң гына максатына ирешә. Болай ашкынуының сәбәбе радиога мөкиббән китүдән генә түгелдер. Хәтта аны пропаганда коралы буларак куллану өчен генә дә түгел. Бу – заманның техник казанышларын татарларга да ирештерергә теләве белән бәйле. Чөнки радио – ул чор өчен бүгенге интернет шикеллерәк нәрсә. Мәдәни-милли тәрбия бирүдә дә аның әһәмияте зур. Шамил дә радио аша музыкаль тапшырулар, концертлар, хәтта спектакльләр оештыра. Язучыларны, шагыйрьләрне чакыра. Төп игътибар сәнгатькә, әдәбиятка юнәлтелә. Хәтта Мәскәү дә «радиогәзит» дип аталган агитацион тапшырулар белән генә чикләнгән бер дәвердә, Шамил радионы милли мәдәниятне таныту коралына әйләндерә. Казан сәхнәсендә чыккан спектакльне иң читтәге татар авылы да ишетерлек итә. Бу дәрәҗәдә эшләгән радио бары тик Америкада, Петербургта һәм Казанда гына була.

:: Шамил Усмановның төп хатасы нәрсәдә?

– Язмышка үзең хуҗа дисәләр дә, бик алай ук түгел бугай. Хәтта машина руленә генә утырсаң да, артык ирекле була алмыйсың: синең белән юл да идарә итә, машина да. Монда да Шамилнең хатасын эзләү дөрес түгелдер. Бу аның язмышы бит инде. Үзе сайлаган юл, үзен сайлаган юл. Казанга кайтмаган булса, бәлки, Сталин тегерменәнә эләкмәгән булыр иде. Язучылар арасыннан шпионнар эзләүгә каршы чыкмаса, иптәшләре арасында системадан канәгатьсезлек белдермәсә, «Бөтенләй чаманы онытты болар», – дип сөйләнмәсә, милли хисләрен яшереп йөртсә… Бәлки исән калган булыр иде… Тик ул бит – Шамил. Ул бит бүтәнчә була алмый. Тоталитар җәмгыятьнең корбаны булу өчен хаталану мәҗбүри түгел, үзең булып калу һәм аек фикер йөртү дә җитә.

:: Инде романга кайтыйк. Аны кайчан укый алырбыз?

– Әзер инде ул. Шулай да беркадәр үземдә тотам әле. Аз гына карап чыгасым килә. Җитди әсәр бит.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

РАВИЛ САБЫР (ХИКӘЯ)

ЕГЕРМЕ ҖИДЕ

Егерме җиде яше тулганда
һәлак булган сеңлем
Земфирәнең якты истәлегенә
багышлыйм.

Бала күңеле дә гел далада гына түгел.

Иртә белән йокыдан уянып-айнып та җитмәгән идем әле, башыма ныклы бер уй кереп утырды. Була бит шундый бер төрле эчке инану, нәкъ менә шул вакытта, нәкъ менә шулай эшләргә кирәк диген, кемнең дә булса, нинди генә сүз әйтүенә карамастан, үзгәрми һәм үзгәрә алмый торган карар-ышаныч. Ул мондый уй иде: бүген әткәй янына барып кайтырга кирәк.

Әткәем күрше авыл зиратында ята минем. Күптән инде, җитмеш тугызынчы елдан бирле. Миңа ул чакта биш кенә яшь иде әле, шулай да хәтеремдә аңа бәйле бик күп вакыйгалар уелып калган.

Без көн саен, басуларны карап-искәргәләп йөргәндә, урманга кереп ромашкалар җыя идек. Ике букет: берсе – әнкәйгә, берсе – әбекәйгә. Белмим, нигәдер әткәй егерме җиде чәчәк җыярга куша иде. Үзе дә нәкъ шулкадәрле җыйгандыр дип беләм. Әбекәй белән бабакай янына барганда өч литрлы банкага салып сөт тә алып барабыз әле. Кечкенә чакта игътибар итмәгәнмендер инде, хәзерге күзәтүчәнлегем генә сиздерәдер: ап-ак ромашкалар, ап-ак сөт, ап-ак автомобиль, әбекәйнең ап-ак чәчләре, ап-ак тәрәз челтәрләре…

Берсендә, бабакайларга баргач, нишләптер аларда каласым килеп китте. Диван артына кереп качтым. И, әткәй эзли инде! Диван артын да карап китте, «күрмәде» генә. Икенче көнне килеп алды тагын үзе.

Иң көчле тәэсирләр калдырган, искә төшергәч, бүген дә тәннәрне чемердәтеп, бала җаннарын кабарттыра торган вакыйга-хатирә исә шул җитмеш тугызынчы елда булды да инде.

Егерме җиденче май. Әнкәй белән бәрәңге утыртып йөрибез. Әткәй – Казанда, укуда. Күзәнәкләр беткән иде, келәттән ике чиләк орлыклык бәрәңге тутырып алдык та, кире бакчага чыгып киләбез. Авылыбызның бер апасы килеп керде. Үзе җылый. Әнкәйгә калтыравык тавыш белән нидер әйтте бу. Мин аңышмыйча калдым. Шул мин ишетмәгән сүзләрдән әнкәйнең кулларыннан чиләкләре төшеп китте: үзе яхшы чалгы белән чабып алган үләндәй җиргә ауды. Теге апа белән әнкәй ишегалды уртасында икәүләшеп үкереп (бүтән сүз таба алмыйм) еларга тотындылар. Шул чакта мин беренче мәртәбә әнкәйнең күзләрендә яшь күрдем.

Икенче көнне: «Бабаңнарга барабыз», – диделәр. Бардык. Ишегалды, өй тулы кеше. Бөтен туган-тумача, күрше-күлән, тагын әллә кемнәр җыелган. Бөтенесе: «И, сабыем», – дип баштан сыйпый. Әнкәй югалды. Бик озак күренми торды ул. Мин: «Әнкәем кайда?» – дип бик нык җылагач, инде үксеп беткәч кенә табылды. «Әйдә, улым», – дип бабайның өенә әйткәләп алып кереп китте. Олы якка уздык. Бүлмә уртасындагы өстәлдә ак җәймәләргә төренгән әткәем ята иде. Күзе йомык. Аның бите һәм аягы гына күренеп тора. Әткәй янына килгәч, әнкәй аның аягын тотып карарга кушты. Тоттым. Аңа кадәр дә, аннан соң да минем шулкадәр өтеп ала торган салкынны сизгәнем юк иде һәм башка булмады да. Хәзер дә, әткәемне искә төшерсәм, бармакларым, учым шул салкынны сизгәндәй була…

Хатирәләр… Ярый әле кеше аларны онытып торырга да сәләтле.

Ә теге башыма ныклы уй килеп кергән иртәне һәм шул иртә белән башланып киткән көнне мин яхшы хәтерлим. Әнкәйнең туган көне иде ул – 4 август.

Ул көнне мине хатын иртә уятты. Тиз генә уяна алмавымның сәбәбе бик гади – йокы туймады. Авырлы иде хатын ул чакта, җүнле-башлы йоклый да алмый иде. Аңа йокы эләкмәгәч… Шулай инде: икең бер кеше бит.

– Әйдә, тор инде, тор. Эш күп бүген. Кунаклар кайтып җиткәнче җыештырынаса, пешеренәселәр бар, – ди хатын.

Әйтерсең, ул әйтмәсә, белмим. Менә шул чакта кереп утырды инде теге уй-карар: бүген әткәй янына барып кайтырга кирәк. Аңа нидер булган.

Бала күңеле – далада, дип дөрес әйтми татар. Бала күңеле – ата белән анада. Яңа гына тәпиләп киткән, теле ачыла гына башлаган баланың беренче сүзе нинди? Күңеле нидә – сүзе шундый. Күргәнегез бармы «дала» дип теле ачылган баланы? Күрмәссез дә. «Әттә» ди ул, «әннә» ди…

Олылар мине, җылак идең, дип сөйлиләр. Әнкәйгә үз гомерендә иң авыр хәбәрләрнең берсен җиткергән теге хатын – хәтерлим әле – миңа кечкенә чагымда: «Кем башына җылыйсың икән син, бала?!» – дип әйтә торган иде. Әткәй исән чак әле бу. Әлеге ахмак сүзләрне мин ул чакта да аңламый идем, хәзер дә аңламыйм. Ничек инде сыңар гөнаһы да булмаган сабыйның җылаганын кемнеңдер башына юрарга була ди?! Нишләп ул җүләр хатынның авызын томалаучы булмады икән?! Хәер, томаларсың хатын-кыз авызын.

Үземне белә белгәннән бирле мин бер курку белән яшим. Мине ташлап китәрләр сыман. Ә кечкенәдән берүзем калырга яратмый идем. Юк, мин караңгы почмактан куркыныч бүкәй килеп чыгып, мине ашап бетерер, дип беркайчан да курыкмадым. Китәрләр дә кайтмаслар кебек иде. Әнкәй хәзер дә сөйли:

– Җокламадың инде, улым, бәләкәйдән җокламадың. Өч яшьлек чагыңнан көтү куып кайтканда каршыга җылый-җылый йөгереп килә идең. Әнкәй, акылың бармы синең, юкмы, нигә мине көтү куарга уятмадың, дип әйтә торган идең, – ди.

Сизенгән инде бала күңеле. Әткәй Казанга укырга киткән җиреннән кайтты да, кайтмады да. Аның кабер ташына, исеме астына мондый саннар язылган:

27.VII.1944 – 27.V.1979.

Мин 27 гыйнварда туганмын. Мартта туасы бала булганмын югыйсә, ашыга-ашыга кышкы суыкларда дөньяга килгәнмен. Табиблар улымны да егерме җиденче февральдә туарга тиеш дигәннәр иде. Ул дүрт көнгә алданрак туды. Хәер, тууын үз вакыты белән тугандыр инде ул, табиблар ялгышкандыр.

Ә теге иртәдә «әткәйгә нидер булган» дип уйлап ялгышмаганмын. Дөрес, моның турында мин кичен генә белдем әле. Көне буе аяк өстендә булдык ул көнне. Һәйбәтләп өйне җыештырдык, ишегалларын, капка төпләрен себерештергәләп тәртипкә китердек. Хатын-кызлар мич каршында кайнаштылар. Ә теге уй бер генә минутка да башымнан чыкмады: «Әткәй янына барып кайтырга кирәк». Тиз генә чыгып китеп тә булмый бит әле, туган көн мәҗлесенә әзерләнәсе бар. Кичкә дүртләргә эшләр беткән сыман булды.

Әткәй ята торган зират сигез чакрым ераклыкта. Гаражга кереп карасам, өч мотоциклның өчесе дә сүтеп ташланган. Тырыша торгач, берсен җыеп кабыздым тагын үзе.

Өйгә кереп, әнкәй белән хатынга:

– Мин әткәй янына барып кайтам әле, – дидем.

– Улым, бүген җөрмә инде, иртәгә барырсың. Абый-апаларың да кайтып җитәр тиздән, – ди әнкәй.

– Юк, – мин әйтәм, – барып кайтам әле. Әллә нишләп күңелем урынында түгел. Озак тормыйм мин, ярты сәгать дигәндә әйләнеп кайтырмын.

– Мин дә барам, – диде хатын.

– Кая?

– Синең белән.

– Матайга утырып, басу юлларынманмы?

– Әкрен генә барырсың.

– Килен, сиңа ярамый бит зиратка керергә, – дип куйды әнкәй.

– Ә мин анда кермәмен. Килеп җитәрәк төшереп калдырырсың, – ди хатын. – Барыйм инде, ә?! Куркам үзеңне генә җибәрергә.

– Ни булсын соң миңа? Әйдә инде алайса, әйдә.

Алдан ук әйтеп куйыйм әле: шәһәрдән кайтасы туган-тумача икенче көнне генә кайтып төште. Ә дүртесендә әнкәй күрше-күләнне чакырды. Хатын белән икәү баштарак кунаклар белән бергә өстәл янына утырдык, әнкәйне матур итеп котлап, бүләкләрне тапшырдык. Озак та үтмәде, теге җүнсез сүз сөйләргә маһир хатын килеп керде. «Туган көнең түгелме соң?» – ди әнкәйгә. Ул, җәелеп, өстәл түренә кереп утыргач, кәеф кырылды. Әнкәйдән гафу үтенеп, иркенләп утырыгыз, дигән булып хатын белән верандага йокларга чыгып киттек.

Көне буена йөгереп арылган, күрәсең, бик тиз йоклап кителгән. Шунда мин бер төш күрдем. Имеш, күк йөзендәге бер йолдыз кисәк кенә бик якты кабынып киткән дә шундук бик зур тизлек белән минем өстемә төшә башлаган. Якынайгач аңладым: бу – егерме җиде саны икән. Өстемә төшеп сыта инде дигәндә… хатын җилтерәтә башлады:

– Уян, дим, уян, саташасың!

Ахыры бар >

КОТЛЫЙБЫЗ!

Буа районы Әхмәт авылында туып-үсеп, хәзерге вакытта Балтачта яшәүче һәм җаваплы хезмәттә булган улыбыз, туганыбыз **ГАЙНУЛЛИН Илдар Гомәр улы**ның 4 гыйнварда 60 яшьлек олы юбилее.

Кадерлебез! Син – һәрберебезгә игътибарлы, олы йөрәкле, изге күңелле, игелекле, ярдәмчел ул, ачык күңелле туган. Гаиләңдә акыллы ир, кайгыртучан әти, дәү әти. Гомереңнең 32 елы хокук сагында үтә. Эшеңдә булдыклы җитәкче, хезмәттәшләреңнең ихтирамын казанып, хезмәт куясың.

Кадерлебез! Сине гомер бәйрәмең белән котлап, ихлас теләкләребезне юллыйбыз: бәрәкәтле озын гомер, нык сәламәтлек, бәхет-шатлык, җаваплы эшеңдә зур уңышлар телибез. Тормыш юлдашың Лилия белән тигезлектә, мул, имин тормышта яшәгез. Балаларыгыз, оныкларыгызның игелеген күреп, якыннарыгызның күңел җылысын тоеп гомер итәргә насыйп булсын.

Иң изге теләкләр белән, әти-әниең, Апаста һәм Буада яшәүче туганнарың

Хәтер-хатирә

«Ученый» ат



Безнең авылда ат белән, арбага төяп, газ баллоны таратучы булып эшләүче Гани абый бар иде. Урыны оҗмахтадыр, яхшы кеше генә анда эләгә. Дөресрәге, Гани абый түгел, аның аты таратты ул баллоннарны. Ат шулхәтле шәп өйрәтелгән өй саен туктап йөргәндә, Гани абый үзе мөгәриччтән кәеф корып, арбада йоклап киткән булыр, ә аты капка төбенә килеп туктый торган иде гадәттә. Газ кирәк кеше, атны күрү белән, чыгып кына ала. Гани абыйны уятып маташмый. Арба бушагач, атны куып җибәрәләр иплән кенә, ә ул хуҗасының капкасы төбенә кайтып, алдан әзерләп куелган утлыктагы печәнен чемченә башлый. Кеше акыллары бардыр үзендә!..

Россиянең күп куллана торган алама арбасына дегет чиләге тагылып барган шикелле инде бу очракта Гани абый, әмма аттан «учёный» ясавы игътибарга лаек!

Алмаз ХӘМЗИН

Беләсең килсә...

1 Hyundai автомобиле логотибы нәрсәне аңлата?
а) ике ярны тоташтыручы күпер;
б) ике кеше күрешә;
в) җир һәм күк арасы.

2 Даль сүзлегендә бу балык «зур елгалар акуласы» дип атала.
а) чуртан;
б) җәен;
в) кырпы.

3 Иң салкын планета:
а) Уран;
б) Нептун;
в) Меркурий.

4 Барон Мюнхгаузен нәрсәгә утырып очкан?
а) атка;
б) ядрәгә;
в) укка.

Җаваплар: 1.б); 2.б); 3.а); 4.б).



Әз-мәз мәзәк

– Йомыркага бәя ник шулай артты икән?
– Белмим, мин сәясәт белән кызыксынмыйм.

***

Мәктәптә:
– Ленар, ник дәфтәреңә берни язмадың?
– Апа, мин – «Гринпис» вәкиле хәзер, табигатьне саклыйм.

***

– Никтер күңелсез.
– Өйләнеп кара.
– Өйләнгәч, күңелле буламы?
– Һәрхәлдә, күңелсез булмый.

***

– Кайда идең син?
– Урамда эт белән йөрдем.
– Этең юк бит синең.
– Урамда таныштым.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: багу, чая, Раннур, тизлек, оту, тыл, Ра, Ми, мут, Аляска, Ту, ул, акыру, фани, ранзания, тоу, ис, тел, МиГ, ки, Налаcа, Оле, аз, йөз, куна.

Вертикаль: батут, томпон, ымлык, Гүзәлия, ыру, Грей, Сара, ре, ун, наз, чак, ат, Ан, Уфа, лак, янкорма, Анит, Азу, тау, унисекс, арту, Талия, Лиана.

Газетаның киләсе саны 10 гыйнварда чыга.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 13856 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 201

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәрриренең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+